ШАЛКАН БӘЯСЕ

Сарык йоны нигә кадерсез?

> 6

САУБУЛЛАШАБЫЗМЫ?

Ата-аналар арасында инглиз телен укытуга каршы чыгучылар да бар

> 15

ТАТАР ЭЗЕ

Галимнәр Бөек Ватан сугышында Белоруссиядә ятып калган бабалары-бызның эзләреннән үтте

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 63 (29030) | Җомга | 5 май | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

БАЛА БЕР, ҺӨНӘР МЕҢ

ДӨРЕС ЮНӘЛЕШНЕ НИЧЕК КҮРСӘТЕРГӘ?

Уңга барасымы, сулга борыласымы? Тиздән күпләргә, аерым алганда, ата-аналарга һәм балаларга шул сорау белән очрашырга туры киләчәк. Казанда яшәүче Насретдиновлар инде җавабын эзли башлаган. Олы кызлары мәктәпне тәмамлый быел. Әнисе – табиб, әтисе – укытучы итәргә, әби-бабай башка һөнәр иясе итеп күрергә тели аны. Кызның хыялы исә бөтенләй башка. Туры юлда таш булып яткан тагын бер нәрсә бар: бу мәктәп баласының санап үткән барлык һөнәрләргә дә сәләте җитәрлек. Киләчәк хәл ителгәндә, ничек ялгышмаска соң? Әнине тыңлыйсымы, күңел кушканны сайлыйсымы?

> 5

Ишетми калмагыз

Татарстанда «Торак һәм шәһәр мохите» илкүләм проекты нигезендә социаль ипотека буенча яңа йортлар төзелә. Шулай итеп, республикада яшәүчеләргә торак шартларын яхшырту мөмкинлеге ачыла.

Торакка Дәүләт торак фонды программаларында катнашучылар – бюджет өлкәсендә эшләүчеләр, программаны тормышка ашыруга акча бирүче оешмалар хезмәткәрләре, ятимнәр, яшь гаиләләр дәгъва кыла. Быел фонд программалары буенча барлыгы 2885 гаиләне торaклы итү күздә тотыла.

Россия банкы быел беренче кварталда Татарстанда законсыз эшләүче 5 «кара» кредиторны ачыклаган. Алар, тиешле документлары булмаган килеш, мөлкәтне залогка алып, бурычка акча биреп яткан. Мондыйларның максаты – әҗәтне процентлар белән түләтү хисабына табышлы булу түгел, бәлки кешене бурычын кире кайтара алмау хәленә җиткерү. Эшләр болайга киткән очракта, мөлкәткә (күчемле һәм күчемсез) арест салына һәм сатып җибәрелә. Шуңа күрә таныш булмаган кешеләрдән әҗәткә алып торырга ярамый. Финанс оешмасына мөрәҗәгать иткән очракта исә аның кредит бирүгә рәсми рөхсәте бармы-юкмы икәнен белешергә кирәк. Моны Россия банкы сайтындагы «Проверить финансовую организацию» бүлегендә ачыкларга мөмкин.

Сүз уңаеннан, оешмаларның исемлеге Россия банкының кисәтү исемлегенә кертелә. Хәзер анда 9 меңнән артыграк компания, шул исәптән Татарстанда эшләп килүче 69 компания бар.

Яз башланганнан бирле төбәк юлларында 180700 кв. метрдан артыграк мәйданда чокыр-чакырларны ямаганнар. Вак таш түшәлгән юлларның 1,5 мең кв. метрдан артыграк өлешен төзекләндергәннәр.

Юл хезмәтләре санитария-экология икеайлыгы кысасында юл читләрен чистарта-җыештыра. Бүгенгә 3 мең куб. м чамасы чүп-чар җыеп алынган инде. 226,7 чакрым озынлыкта юлларга буй-буй сызыклар, башка тамгалар ясалган.

Быел Татарстанда юл эшләре программасына барлыгы 67 миллиард сумнан күбрәк акча каралган. Шуның 14 миллиард сумнан артыгрaгы – Россия бюджетыннан һәм 53 миллиард сум чамасы – Татарстан бюджетыннан.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, туристларны авыл хуҗалыгы оешмаларына җәлеп итү өчен, «Агротуризм» грантын алуга бәйге игълан иткән. Туризм буенча Дәүләт комитеты хәбәренә караганда, грант туризм ярдәмендә үз продукциясен күбрәк сатарга ниятләүче җитештерүчеләр өчен булдырылган. Туризмнан алынган гомуми керем авыл хуҗалыгы продукциясен сатудан кергән акчаның 25 процентыннан артмаска тиеш. Дәүләт ярдәме бер хуҗалыкка 3 миллион сумнан 10 миллион сумга кадәр тәшкил итә. Гаризалар 8 майга кадәр кабул ителә.

Районнарда ни хәлләр?

Биектау

Узган елның ноябрендә Айбаш авылындагы мәчетнең манарасын җил аударган иде. Шушы көннәрдә мәчет бинасын төзекләндерүнең беренче этабы башланган. Республиканың Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты рәисе Иван Гущин авылга сәфәре барышында шул хакта хәбәр итте. «Төзекләндерү эшләренә иганәчеләр ярдәмендә 25 миллион сумга якын акча таптык. Барлыгы 50 миллион сумга якын акча сарыф ителәчәк», – диде Гущин. Аның сүзләренчә, мәчеттәге ремонт эшләре бюджет хисабына түгел, ә иганәчеләр күчергән акчага алып барыла. Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин исә ремонт вакытында намаз уку өчен вакытлы корылма торгызылганлыгын хәбәр итте.
(«Татар-информ»)

Әлмәт

Бу елның апрель аенда Әлмәттә 137 бала туган. Аларның 74е – малай, 63е – кыз. Бу хакта Әлмәт ЗАГСы хәбәр итә. Иң яшь әнигә – 18, иң өлкәненә 48 яшь булса, иң яшь әтигә – 21, ә иң өлкәненә – 53 яшь. Әтиәниләр яңа туган сабыйларына Әминә, Ясминә, Әмир кебек исемнәр куша икән. Бу айда иң сирәк кушылган исемнәр арасында Физалия, Хәйдәр, Алисия, Румил, Мелания, Сабир, Әдил, Һаҗәр, Хәсән, Хөсәен, Камалия бар.
(«Әлмәт таңнары»)

Чирмешән

Чирмешәндә беренче тапкыр Пенсионерлар спартакиадасы оештырылды. Бөек Җиңүнең 78 еллыгына багышланган әлеге ярышларда йөзү, йөгерү, пневматик винтовкадан ату, өстәл теннисы һәм дартс буенча көч сынаштылар. «Физкультура-сәламәтләндерү комплексында узган әлеге чарада районның төрле авылларыннан тугыз команда, барлыгы 50гә якын кеше катнашты», – диде район Ветераннар (пенсионерлар) советы рәисе Миләүшә Батыршина. 10 кешедән торган иң зур команда Лашман авылы җирлегеннән килгән иде. Иске Үтәмеш, Бәркәтә, Ульяновка, Кармыш, Чирмешән, Иске Кади, Утыз Имән авылларыннан да катнашучылар бар иде. Спартакиаданың иң өлкән катнашучысы булып Иске Кади авылыннан килгән Мингосман Мортазин танылды.
(«Безнең Чирмешән»)

Мамадыш

Шәдче авылында гомер кичерүче Рәисә һәм Фаил Фәизовлар махсус хәрби операциядә катнашучыларга 70 мең сум акча җибәргән. Пенсияләреннән җыеп барган акчаларын «Своих не бросаем» хәйрия фондына күчергән алар. Фәизовларның оныгы Марат Абилов хәзерге вакытта Луганскида хезмәт итә. «Көн дә егетләребезнең туган якларына исән-имин килеш кайтуларын сорап, Аллаһы Тәгаләгә ялварабыз», – диләр Рәисә апа һәм Фаил абый. Сүз уңаеннан, гаилә башлыгы – Шәдче авылы мәктәбендә балаларга хәрби дәресләр укыткан, яшь буынны патриотик рухта тәрбияләүгә үз өлешен керткән кеше.
(«Нократ»)

САКЛАР ҺӘМ КАЙГЫРТЫР ЧАК

Тарихны бозып күрсәтүгә юл куярга хакыбыз юк. Без тарихи хәтерне балаларыбызга, оныкларыбызга да җиткерергә бурычлы. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек һәм аны уздыру буенча оештыру комитеты утырышында шулай дип белдерде. Утырышта Россия хәрби-тарихи җәмгыяте рәисе урынбасары Николай Овсиенко да катнашты.

tatarstan.ru

Муса Җәлил исемендәге опера һәм балет театрында Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тантаналы чара узды. Анда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен тапшырды. Аерым алганда, «Россия Герое» исеме үлгәннән соң өлкән лейтенант Олег Сорокинга бирелде. «Алтын йолдыз» медален аның әти-әнисенә тапшырдылар. Батырлык орденнары белән үлгәннән соң өлкән лейтенант Герман Захаров һәм рядовой Фәнил Хисмәтуллин бүләкләнде. Рәис кулыннан бүләкләрне аларның туганнары алды (фотода Фәнил Хисмәтуллинның тол хатыны Гөлзия һәм улы Ибраһим).

– Соңгы елларда геосәяси вазгыять ничек кенә үзгәрсә дә, 9 Май иң кадерле, яраткан, бөек бәйрәм булып кала бирә. 1945 елның 9 Маенда совет гаскәрләре, фашист режимы золымын җиңеп, канкойгыч сугышка нокта куйды. Бу дата атабабаларыбызга дан, милли горурлык символы, чиксез рәхмәт һәм мәңгелек хәтер көненә әверелде. Бу көнне безнең җирләрне азат итү өчен гомерләрен корбан иткән, тылда Бөек Җиңү көнен якынайткан ул һәм кызларыбызны зур рәхмәт хисләре белән искә алабыз. Без тарихи хәтерне, Җиңүнең нинди зур сынаулар аша бирелүен балаларыбызга, оныкларыбызга да җиткерергә бурычлы. Тарихны бозып күрсәтүгә юл куярга хакыбыз юк, – дип белдерде Татарстан Рәисе.

Рөстәм Миңнеханов Бөек Ватан сугышы елларында республиканың иң мөһим тыл үзәкләренең берсе булуын да искәртте. Әйтик, Казанның химия заводы кыска вакыт эчендә фронт өчен 22 төрле химикат эшләп чыгарган. Кукмараның киез итек-киез басу комбинаты сугыш вакытында 1,5 миллион пар аяк киеме җитештергән, 6 миллион пар аяк киемен яңарткан. Рөстәм Миңнеханов сүзләренә караганда, бүген республикада Бөек Ватан сугышы елларында хәрби һәм гражданлык продукциясен өзлексез җитештерүне тәэмин итүгә зур өлеш керткән 20 оешма исәпләнә. Алар барысы да «Хезмәт батырлыгы оешмасы» исеменә лаек булдылар.

– Дәүләт оборона заказын тулы күләмдә һәм вакытында үтәү – безнең өстенлек. Россия Президенты Владимир Путин да барлык бүлекчәләрне кыска вакыт эчендә яхшы сыйфатлы корал, техника, җиһазлар һәм сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итүне оборона-сәнәгать комплексының төп бурычы дип атады, – дип белдерде Рөстәм Миңнеханов. – Бүген ватандашларыбыз махсус хәрби операциядә катнаша. Анда катнашкан һәркем батырлык һәм каһарманлык, патриотик рух, Ватанга тугры хезмәт итү үрнәге булып тора. Муниципаль районнар һәм шәһәр округлары, министрлыклар һәм ведомство башлыкларына чараларда махсус хәрби операциядәге егетләрне дә җәлеп итәргә кушам.

Рөстәм Миңнеханов билгеләп үткәнчә, бүген республикада 14 меңнән артык Бөек Ватан сугышы ветераны яши. Кызганыч ки, аларның сафы елдан-ел кими бара. Чагыштыру өчен: 2020 елда республикада 33 меңнән артык Бөек Ватан сугышы ветераны яшәгән.

– Безнең һәр ветеран үзен кайгыртуларын сизеп торырга тиеш. Җиңүнең 78 еллыгын бәйрәм итүгә бәйле чаралар ел дәвамында үткәрелә. Ләкин 1 майдан 9 майга кадәрге чорда кешеләр бергә җыела торган чаралар аеруча күп уздырыла. Шуңа күрә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгына, Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына, Сәламәтлек саклау министрлыгына барлык планлаштырылган чараларны тәэмин итүне йөклим, – диде Рөстәм Миңнеханов.

Татарстан Рәисе планлаштырылган илкүләм һәм республика акцияләрен дә югары дәрәҗәдә уздырырга боерды. Бөек Җиңүнең 78 еллыгы уңаеннан бәйрәм тантанасы Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театрында дәвам итте.

ТАРИХ БҮГЕН ЯЗЫЛА

Бер көндә – ике һәйкәл. Казанның Төньяк вокзалы янында биеклеге 26 метрга җиткән «Казан – хезмәт батырлыгы шәһәре» стеласы, ә Арча зиратында Советлар Союзы Герое Борис Кузнецовка һәйкәл ачылды. Әлеге чараларда Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та катнашты.

Үткәнен белмәгәннең киләчәге юк. Җиңү көне якынлашкан көннәрдә бу сүзләрнең мәгънәсе тагын да тирән яңгырый. Стела ачылуны да республика һәм тулаем ил өчен мөһим, тарихи вакыйга дип бәяләде тантанага җыелучылар. Исегезгә төшерәбез: Россия Президенты Владимир Путин Указы нигезендә әлеге югары исемгә илнең 53 шәһәре лаек.

– Татарстан Бөек Ватан сугышы елларында илнең иң мөһим тыл үзәге булды, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Идел буена эвакуацияләнгән 226 предприятиенең 70тән артыгы безнең республикада урнаштырылган. Фронт өчен 600 төрдән артык корал, сугыш кирәк-яраклары, җайланмалар җитештергәннәр. Аерым алганда, Пе-2, Пе-8, У-2 очкычлары, артиллерия һәм ату кораллары өчен зарядлар, армия, авиация һәм флот өчен җиһазлар чыгарылган. Хатын-кызлар, балалар һәм өлкәннәр хәлдән килгәнчә тырышканнар. Һәркемгә «Барысы да фронт өчен! Барысы да җиңү өчен!» шигаре иң мөһиме булган.

Рәис Татарстан предприятиеләренең хезмәт батырлыгын мәңгеләштерү максатыннан республикада «Хезмәт батырлыгы предприятиесе» исеме булдырылуын да әйтте. Әлеге дәрәҗәле исем республикадагы 20 предприятиегә бирелгән.

– Бүген стеланы ачу тантанасында предприятие коллективлары катнаша, алар хәзер дә махсус хәрби операция бурычларын тулы җаваплылык һәм фидакарьлек белән үтиләр. Без җиңәчәкбез! – диде Рөстәм Миңнеханов.

Форсаттан файдаланып, Рәис ветераннарга хезмәт батырлыклары өчен рәхмәт әйтте һәм якынлашып килүче Җиңү көне белән котлады.

Шул ук көнне Арча зиратында Советлар Союзы Герое Борис Кузнецовка һәйкәл ачылды. Рөстәм Миңнеханов аны «легендага әверелгән шәхес» дип атады.

– Татарстан һәрвакыт үз иленә тугры булган сугышчылар белән дан тотты, – диде Рәис. – Республикада туган 185 кеше һәм язмышы Татарстанга бәйле булган 168 кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек.

Бүген дә Җиңү Байрагын шул коточкыч сугыш геройларының варислары – Россия армиясе хәрбиләре йөртә, дип белдерде Рөстәм Миңнеханов. Ул искәрткәнчә, Татарстанда яшәүче 26 кешегә Россия Герое исеме бирелгән, 7 хәрби бу югары исемне махсус хәрби операция барышында алган.

Эльвира ВӘЛИЕВА

БЕРДӘМЛЕК КӨЧЕ

Авыр техника һәм медицина җиһазлары белән тәэмин итү, әтиләре яу кырында булган балаларның җәйге ялын кайгырту. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов махсус хәрби операциядә катнашучыларның гаиләләрен һәм республикадан мобилизацияләнгән хәрбиләрне борчыган мәсьәләләрне тыңлады.

tatarstan.ru

Рөстәм Миңнеханов Хөкүмәт йортында Ватан сугышчылары гаиләләре комитетының республикадагы төбәк штабы вәкилләре белән очрашты. Исегезгә төшерәбез: Ватан сугышчылары гаиләләре комитеты – хәрбиләрнең гаилә әгъзаларын берләштерүче иҗтимагый хәрәкәт. Аның оешуы турында 2022 елның ноябрендә Россия Президенты хәрбиләрнең әниләре белән күрешкән вакытта билгеле булды. Рәис катнашындагы чарада төбәк штабының хакимият вәкилләре белән хезмәттәшлеге, республикадан мобилизацияләнгән хәрбиләрнең мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклау кебек мәсьәләләр күтәрелде. Шулай ук хәрби хәрәкәтләрдә катнашучыларны реабилитацияләү, аларның гаиләләренә социаль ярдәм кебек сораулар турында да фикер алыштылар. Ирләрен махсус хәрби операциягә озаткан хатын-кызларны балаларга медицина, психологик ярдәм күрсәтү, җәйге ялны оештыру кебек мәсьәләләр дә борчый. Рөстәм Миңнехановка бу хакта да сөйләделәр. Очрашу барышында башка иҗтимагый оешмалар белән элемтәләрне ныгытуның әһәмияten дә билгеләп үттеләр.

Чарада Рәис Администрациясе җитәкчесе Әсгать Сафаров, Премьер-министр урынбасары Ләйлә Фазлыева, Ватан сугышчылары гаиләләре комитетының төбәк штабы җитәкчесе Ангелина Галимова, Махсус хәрби операциягә ярдәм итү волонтерлык хәрәкәте җитәкчесе урынбасары һәм оештыручысы Марина Куцакова да катнашты.

Тагын бер җитди сөйләшү махсус хәрби операциядә катнашучыларның үзләре белән узды. Рөстәм Миңнеханов хәзерге вакытта ялга кайткан Татарстаннан мобилизацияләнгән хәрбиләр белән очрашты. Ул аларны сәламләп, кылган батырлыклары өчен рәхмәт әйтте.

– Без теләсә нинди хәлдә дә һәрвакыт сезнең белән, – диде Рәис.

Җавап йөзеннән, хәрбиләр республика җитәкчелегенә, район башлыкларына, Татарстан оешма-предприятиеләренә даими ярдәм күрсәтеп торулары өчен рәхмәт белдерделәр. Алар махсус хәрби операция зонасына хатлар, шигырьләр, рәсемнәр юллаучы балаларга да аерым рәхмәтле. «Бу безнең өчен бик мөһим», – диде солдатларның берсе, күңелендәге хисләрен җиткереп.

Сөйләшү барышында хәрбиләр даими кулланылышта булган һәм яңартуны таләп итүче техника белән тәэмин итү мәсьәләсенә аерым тукталды. Мәсәлән, «вездеход»лар, шул исәптән яралыларны чыгару өчен дә, авыр техника һәм аларга запас частьлар кирәк. Хәрбиләргә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтү өчен дефибрилляторлар җитмәвен дә әйттеләр.

– Ышандырып әйтә алам: без һәрвакытта да сезгә ярдәм иттек һәм алга таба да булышачакбыз, – диде Рәис. – Ил өчен башкарганрыгызны без сезгә беркайчан да түләп бетерә алмаячакбыз. Мөмкин кадәр ярдәм итәчәкбез!

КОТЛЫЙБЫЗ!

Халыкны социаль яклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Татарстан Республикасының Анжела Вавилова исемендәге лейкемия авыруыннан интегүче балаларга ярдәм итү буенча төбәк иҗтимагый хәйрия фонды идарәсе рәисе **Вавилов** Владимир Владимирович **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Пирогов ордены** белән бүләкләнде.

***

Илебезнең мәдәнияten һәм сәнгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, күп еллар буе нәтиҗәле эшләве өчен «Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры» дәүләт бюджет учреждениесенең балет буенча сәнгать җитәкчесе **Яковлев** Владимир Алексеевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Почет ордены** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефть-Добыча» структур подразделениесе «Нурлатнефть» нефть-газ чыгару идарәсенең җир асты катламнары басымын саклау буенча операторы **Тямаев** Рәшит Барый улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Мәгариф өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «В.П. Лушников исемендәге Казан нефть химиясе көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе директоры **Шәмсетдинов** Илдар Гыйлаҗетдин улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Хезмәттәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы кулланучылар кооперациясе оешмалары берлеге» коммерциясез оешмасы идарәсе рәисе **Шаймәрданов** Рашат Рифкать улы **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» II дәрәҗә ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Казан шәһәре «16 нчы шәһәр клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең баш табибы урынбасары **Кривошапко** Сергей Валерьевич **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә Лука Крымский медале** белән бүләкләнде.

***

Производство эшчәнлегендә югары күрсәткечләргә ирешүе өчен **«Серго исемендәге завод» производство берләшмәсе» акционер җәмгыяте коллективы Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Хезмәттәге уңышлар өчен» Россия Федерациясе мактау билгесе** белән бүләкләнде.

***

Сәламәтлек саклау өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Республика клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесе бүлек мөдире **Одинцова** Әлфия Харис кызына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган табибы»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Нефть һәм газ сәнәгате өлкәсендәге казанышлары, күп еллар буе намус белән эшләве өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыятенең «Татнефтегазпереработка» идарәсе контроль-үлчәү приборларына һәм автоматикага техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау хезмәте өлкән мастеры **Кашапов** Галимҗан Таһирҗан улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган нефть һәм газ сәнәгате хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Авыл хуҗалыгы өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «Урал» авыл хуҗалыгы производство кооперативы рәисе **Хәбибрахманов** Газинур Хәтим улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Төзелеш өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен «ПРОФИТ» компанияләр төркеме» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Мингалимов** Марсель Җәвит улына **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган төзүчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

***

Химия сәнәгате өлкәсендәге казанышлары һәм күп еллар буе намус белән эшләве өчен Түбән Кама «Нефтехим» гавами акционерлык җәмгыятенең олигомерлар һәм гликольләр заводы кудыру аппаратчысы **Вәлиев** Әдхәт Габделбарый улына; Түбән Кама «Нефтехим» гавами акционер җәмгыятенең автоматлаштыру узәге контроль-үлчәү приборлары һәм автоматика буенча слесаре **Галкин** Сергей Николаевичка **Россия Федерациясе Президенты Указы нигезендә «Россия Федерациясенең атказанган химигы»** дигән мактаулы исем бирелде.

БЕР ГАСЫРЛЫК БӘЙРӘМ

Массакүләм спорт хәрәкәтенә башлангыч бирүчеләр! Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов «Динамо» бөтенроссия физкультура-спорт җәмгыятенең 100 еллыгы уңаеннан үткәрелгән тантаналы чарада бәйрәм хуҗаларына әнә шундый зур бәя бирде.

Казан Кремлендә узган тантанада Татарстан Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан Премьер-министры Алексей Песошин, Татарстан Рәисе Администрациясе җитәкчесе, «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте рәисе Әсгать Сафаров та катнашты.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, бүген «Динамо» – илнең барлык төбәкләрендә эшләп килүче иң зур спорт оешмаларының берсе.

– Олимпия уеннары, дөнья, Европа һәм ил күләмендә күп тапкыр чемпион исеменә лаек булган динамочыларның исемнәре бөтен дөньяга билгеле, – диде ул.

Бәйрәмдә данлыклы Татарстан динамочыларын да искә алдылар. Алар арасында – Светлана Данилова, Евгения Дементьева, Максим Вылегжанин, Андрей Ларьков (чаңгычылар); Анастасия Колесникова, Дмитрий Древин (гимнастлар); Гөлнара Галкина-Сәмитова, Юлия Зарипова (җиңел атлетлар); Марта Мартьянова (фехтование остасы); Яна Мартынова (йөзүче); Сергей Тетюхин, Екатерина Гамова (волейболчылар) да бар.

– Спортның уен төрләрендәге уңышлар – аерым горурлыгыбыз. Безнең ир-атлар һәм хатын-кызлар волейбол командалары күп тапкырлар илдә, Европада һәм дөньяда беренчелекне алды, – диде Рәис.

Ул туплы хоккей буенча күп тапкыр чемпион исеменә лаек булган «Ак Барс – Динамо» командасының уңышларын, чирәм хоккее буенча 20 тапкыр ил чемпионы булган «Динамо-Ак барс» ирләр клубын һәм ике тапкыр ил чемпионы, Россия Кубогы һәм Суперкубогы иясе «Ак барс – Динамо» хатын-кызлар клубын да аерым билгеләп үтте. Рөстәм Миңнеханов оешма рәисе Әсгать Сафәровка, спорт клублары җитәкчеләренә, тренерларга һәм барлык хезмәткәрләргә тырыш хезмәтләре өчен рәхмәт белдерде.

– Спортчылар югары нәтиҗәләр һәм спорт осталыгы күрсәтә. Татарстан – лаеклы рәвештә илнең спорт төбәге, ә Казан спорт башкаласы исемен йөртә. Бу эштә «Динамо» республика җәмгыятенең дә өлеше зур, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Әлбәттә, безнең төп бурыч халыкны сәламәт яшәү рәвеше алып барырга, физик культура һәм спорт белән шөгыльләнергә этәрүдән гыйбарәт. «Динамо» бу бурычны үтәүгә зур өлеш кертә. Спорт җәмгыятенең бер гасырлык юбилее белән котлыйм.

Әйтеп кенә бактым

Стресс

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Каян таптылар шул хәерсезне: табиблар әйтүенчә, мин инфаркт кичергәнмен икән. «Кайчан?» – дип сорагач, төгәл генә вакытын әйтә алмадылар. Гомумән, бу мөмкин түгел эш икән. «Ну, аяк өсте үткәргәнсез, это – факт», – диделәр. Шул «факт»ны әллә нишләр эшләтәсе килеп китте, тик миңа нервыланырга да ярамый, инфарктның кире кайту ихтималы бар икән. «Тогда что?» – дигән идем, кыска гына итеп: «Тогда – крышка», – диделәр. «Крышка» булмасын өчен күбрәк җәяү йөрергә, стресстан сакланырга киңәш иттеләр. Киңәш итү ансат ул. Җәяү йөрерсең дә инде, ә менә стресстан ничек качарга? Без һәр нәрсәне күңелгә якын алырга өйрәнгән шул, туң йөрәк түгел, дип әйтүем. Күңелдән чыккан гына күңелгә барып җитә, дип язып яткан булабыз.

Стресс турында хатынга да әйтеп куйдым: «Миңа каты кагылма, авыр сүз әйтмә!» – дидем. Аның бит дөньялары бер дә тыныч түгел. Әле күптән түгел туган якларга Украинадан ике якташымның үле гәүдәсен алып кайтканнар дип ишеттем. Стрессмы бу? Стресс. Такташчарак итеп: «Зеленскийның сатыйм анасын…» – дип куясы килә. Әмма аның кемнәрдер кулында бер курчак кына икәнен искә төшерәм дә вакланып торасы килми. Ә стресс кичерәм. Җиңү көне алдыннан Бөек Ватан сугышы ветераннары белән очрашып сөйләшеп утырасы килгән иде. Баксаң, алар бүген бармак белән генә санарлык икән. Мин алгы сызыкта булганнарны, сугышта турыдан-туры катнашканнарны күз алдында тотам инде. Икенчедән, ветераннарыбызның балалары ватан солдатларын стресстан сакларга тели. «Гафу ит инде, Риман абый, аларга дулкынланырга ярамый, шундук кан басымнары күтәрелә, каефләре китә», – диләр. Интернетка кереп, «Стресстан ничек качарга була?» – дип язып карыйм. Киңәш бирүчеләр күп икән ул, тик акча сорыйлар. Йә кыйммәтле дарулар тәкъдим итәләр. Болары реклама инде. Бушлай гына киңәш бирүче юк. Монысы – тагын стресс. Аның «стресс» дигән сүзе үк бүген безгә дошман булган дәүләт телендә икән. Инглизчәдән тәрҗемә иткәндә «артык йөк», «басым», «киеренкелек» дигәнрәк мәгънәне аңлата. Россияне Җир йөзеннән юкка чыгару өчен берләшкән дәүләтләрне күз алдына китерәм дә янә стресс кичерәм. Тизрәк тынычланасы да килә. Аз гына булганда елан агуы да дару икәнен искә төшерәм дә, чамадан узмаса, стресс кешегә файдалыдыр да әле, дип уйлап куям. Бит авырлыклар кешене чыныктыра, күңелсезлекләргә каршы тору сәләтен арттыра. Ярый әле «иммунитет» дигәннәре инглиз, немец йә француз сүзе түгел икән, латинчадан тәрҗемә иткәндә «азат булу», «котылу» дигән мәгънәне аңлата. Кара әле, термин-төшенчәләрнең күбесе безгә чит телдән керә икән бит. Яхшысы да, яманы да читтән агыла икән, бу – шулай ук стресс. Нәрсә генә үзебезнеке соң безнең?

Стресс димәктән, аның яхшысы да, яманы да була, диләр. Мәсәлән, гашыйк булсаң, өйләнеп җибәрсәң, бу – файдалы стресс. Әлбәттә, нинди хатын туры килә инде. Шөкер, минеке әйбәт булып чыкты. Хәер, без гомер буе бер-беребезне тәрбияләп яшибез һәм икебезнең дә «дрессировка»га җиңел бирелүебез файдалы стресснең нигезе дип уйлыйм. Галимнәр әйтүенчә, стресстан котылуның җиңел генә ике юлы бар. Әгәр тормышыңда авыр гына бер проблема туып, син аны хәл итүеңә ышанасың икән, димәк, борчылыр сәбәп юк, мәсьәләне тыныч кына хәл ит. Әгәр проблеманы чишә алмавыңны беләсең икән, ул хакта бөтенләй берни дә уйлама, кул селтә. Бу киңәш кайсы галимнекедер, белмим, ну адәм акыллары бар икән үзендә. Ягъни артык уйланмасаң, бернинди стресска да бирешмәячәксең. Тик менә тормышка гамь бетеп, берни дә уйламый яши башласаң, бу якты дөньядан ваз кичү, ник туганыңа үкенү була инде. Монысы да – стресс. Минем әтием Бөек Ватан сугышы ветераны иде. Күпме авырлыклар күрсә дә, соңгы мизгелләренә хәтле тормышны, кешеләрне һәм, әлбәттә, әнине, безне яратты ул. Инде шактый өлкән яшьтә булса да, әнигә мәхәббәт шигыре дә язды. Ул шигырьне бүген көйгә салып җырлыйлар. Әй, чукынып китсен лә стресслары, әти җырын көйләсәм, стресснең «с» хәрефләре дә калмас:

Яшик әле, якты дөнья – бездән,
Без дөньядан әле туймаган…

ЧЫНЛЫКТАН ДА ЧЫНРАК БАЛЛАДА

Укучылар, бәлки, хәтерли торганнардыр: бу юлларның авторы Бөек Җиңү алдыннан классикага әйләнгән сәнгать әсәрләренә – кинофильмнарга, әдәби әсәрләргә мөрәҗәгать итә, шуларны искә алып моңлана. Якынлашып килүче Җиңү көне быел башка елларга караганда үзгәрәк. Үткән көз тыныч тормышны, гаиләләрен, балаларын, әти-әниләрен калдырып, байтак ир-егет ут эченә китте. Инде аларның байтагы ялга кайтып, гаиләләре кочагында булды, яңадан хезмәт урынына юнәлде. Күз яшьле очрашулардан соң кабат шунда юл тотканнар арасында инде корбаннар да бар. Безнең күрше авылдан ике ир – шул корбаннар исемлегендә. Никадәр драма уйнала тормышта, никадәр фаҗига! Аянычы шунда: бәхетсезлекләрнең очы-кырые күренми.

«Российская газета»ның телеграм-каналын ачуга, күзгә ике хәбәр килеп бәрелде. Краснодар краенда нефть базасы яна. Янгынның мәйданы – 1,2 мең квадрат километр. Алдагы көннәрдә генә Севастопольдә шундый янгын булды: мең квадрат метрда ягулык резервуарлары дөрләгән иде. Брянск өлкәсендә тәүлек эчендә икенче локомотив рельслардан төште, вагоннар ауды. Составлар икесе дә махсус хәрби операциягә йөк ташучылардан. Махсус хәрби операция террор актлары рәвешендә Россия төбәкләренә җәелә һәм югалтуларга каршы чара табып бетереп булмый. Автор рәсми хәбәрләрне генә файдалана, фейкларга игътибар итми. Без моннан сиксән елга якын элек булган шартларга параллель вазгыятьтә яшибез, шуңа күрә Икенче Бөтендөнья сугышы вакыйгалары да яңача күзаллана. Сәнгать әсәрләре дә бөтенләй башка күзлектән карала: фаҗига сиңа якыная, аны җаның-тәнең белән тоясың.

Совет чоры сәнгатенең шундый бер үзенчәлеге бар иде: иҗат иткәндә, бик туарыла алмыйсың. Цензура бугаздан ала. Нәтиҗәдә бик күп ура-патриотизм белән сугарылган әсәрләр мәйданга чыга. Аларда сугышның фаҗигале асылы артка чигә, патетика, күтәренке романтик тасвирлау, романтика өстенлек итә. Яшь буында иллюзия туа, тиктомалдан батырлык эшләү гипертеләгә уяна. Табигый хисләр юыла. Әмма совет чоры сәнгате, бернигә карамастан, шундый әсәрләр дә бирде: алар үз вакытында халыкара танылу гына алып калмады, бүген дә йөрәккә үтеп керә, чөнки аларда тормыш сурәтләнә. Тарихның борылган мизгелләрендә исә тормыш чынлыгы әдәби уйдырмага караганда күпкә өстенрәк, күпкә калкурак. Озынга киткән сүз башын түзеп укыган укучы сизенә торгандыр: бүген сүз «Солдат турында баллада» фильмы турында барачак. Әйе, әйе, сугыш кырында көтелмәгән батырлык эшләп, орден урынына әнисен күрү һәм өй түбәсен ремонтлап килү өчен отпуск сораган унтугыз яшьлек Алексей драмасы турында сөйләшергә тели автор. Фильмдагы вакыйгалар хәзерге көнгә үзәк өзгеч параллель белән тоташалар. Параллельләр сюжет белән генә тәгәлләнми. Фильмны төшерүче режиссер Григорий Чухрайның язмышы да хәзерге көнгә аваздаш. Россиядә тарихны алдан әйтеп булмый, диләр бит. Сәнгать әсәренә бәя дә шулай ук: диаметраль капма-каршылыктан торырга мөмкин. Фильм 101 халыкара приз белән бүләкләнә, Канн фестиваленең махсус призын ала, итальян кинорежиссеры Паоло Пазолини аны «классиканың могҗизасы» дип атый, Американың мәшһүр актрисасы Лайза Минелли аны үсмер чагында, кайта-кайта, алты кат карый. Болар барысы да соңрак. Аңарчы Чухрайны Совет армиясен хөрмәт итмәүдә гаеплиләр. Тавыш чыга, милиция чакырталар. Студиянең гомум җыелышында фильм гаепләнә, режиссер партиядән чыгарыла. Ул чорда партиядән чыгарылу – синең алдыңда барлык ишекләр дә ябылды дигән сүз. Әсәреңә «совет чынбарлыгын бозып күрсәтә» дигән тамга алса, иҗатчы буларак син беттең.

«Солдат турында баллада»га һәм аның авторына язмышта кискен борылыш әзерләнеп куелган була ләкин. Төшерүчеләрдән кемдер фильмны Алексей Аджубейга – «Известия» газетасының редакторына күрсәтә. Совет чорында «Известия»нең нәрсә икәнен бер сүз белән генә аңлатып булмый. Берничә шундый төп газета бар: аларның редакторлары илнең иң югары сәяси элиталары катлавына керә. Аджубей – газета редакторы гына түгел, ил җитәкчесе Хрущевның кияве дә. Хрущев фильмны караганда, безнең кебек тетрәнгәнме һәм елаганмы – анысы мәгълүм түгел, әмма «Баллада»ны Канн фестивалена җибәрергә нәкъ менә ул әмер бирә. Бер елдан Чухрай Ленин премиясе ала, партиядә торгызыла. Нәрсәгәдер бәя биргәндә, гомуми шаукымга, гомуми психозга иярергә ярамавын искәртә бу хәлләр безгә.



«Солдат турында баллада» фильмыннан screenshot

Фильмның кыскача сюжетын искә төшерик әле. Катерина Скворцова авыл юлына чыгып баса. Шул юлдан аның улы фронтка китә. Һәм фронттан ялга кайтып, бернничә минутка гына әнисен күрү бәхетенә ирешә. Сугыштан әйләнеп кайтырга вәгъдә бирә, ләкин вәгъдәсен үтәми. Объектив рәвештә үти алмый. Фильм башында кадр артындагы тавыш аның чит илдә һәлак булуын һәм җирләнүен хәбәр итә. Драма менә шулай башланып китә.

Фильмның кульминациясе исә 19 яшьлек элемтәче Алешаның (Алексей Скворцовның) ике немец танкын яндыруы белән башланып китә. Шул батырлыгы өчен орден урынына әнисе белән күрешү мөмкинлеге сорый да инде ул һәм алты көнгә отпуск ала. Аның белән хезмәт итүче Сергей Павлов тылдагы хатынына хәбәр һәм ике кисәк сабын тапшыруны үтенә. Менә шул ике кисәк сабын һәм Павловның башкага кияүгә чыккан хатынына бәйле эпизод Чухрайның карьерасын җимереп ташлый яза да инде. Фильмда Совет армиясен «дискредитацияли» торган башка эпизодлар да бар, әлбәттә. Товар вагонына утырырга омтылган Алешадан сакчы Гаврилкин бер банка тушенка белән ришвәт ала. Вагонда егетне Шура исемле кыз белән тоткач, тагын ике банка кыса. Бары тик Алешаның батырлыгын ишеткән Совет армиясе лейтенанты гына егетне сакчы башбаштаклыгыннан аралап алып, вагонда барырга рөхсәт итә. Шура белән Алеша арасында романтик мәхәббәт уяна, әмма егет кызга яратуы турында әйтергә өлгерми. Фильм соңга калу эпизодларыннан тора. Егет станциядә су алырга чыккач, поездга утырырга соңга кала. Һәм иң аянычы: әнисе белән күрешү вакыты бернничә минутка кадәр генә калып кыскара. Ялның төп өлешен юл маҗаралары йотып бетерә.

Фильмның язмышы да, сюжеты да гыйбрәтле. Ул безне көн вакыйгаларына башка югарылыктан карарга өйрәтә. Иң мөһиме: сугышта романтика юк, фаҗига генә барлыгын аңлата. Көчләрне һәм тырышлыкны шундый фаҗигаләр кабатланмасын өчен тупларга чакыра. Чакыра чакыруын, ләкин, кызганычка, тарих тырма өстендә биюләрдән тора шул. Хакыйкать артык ялангач булып тоела һәм без аңа карарга куркабыз. Эш узып, яшәеш драмага әверелгәч, хакыйкать яшерелә дә, аңа караудан тыялар.

Тема татар әдәбиятында Әмирхан Еникинең «Бер генә сәгатькә» хикәясендә дә яңгыраш таба. Ул хикәянең язылу тарихын белә мин. Сюжеты – тормыштан. Әгәр дә безнең татарда кино сәнгате булса, «Кем җырлады?» хикәясе сценарийга әйләндерелеп, киносюжет төшерелер иде. Талантлы кул белән эшләнсә, «Солдат турында баллада»дан ким булмас иде. Хәзер Канн фестивалендә дә, башка конкурсларда да бөтенләй бүтән критерийлар өстенлек итә. Шуңа күрә табигый хисләрне җырлаган ленталар аларда бүләк ала алмаслар инде. Әмма чор тилерүе артта кала ул, хакыйкать барыбер өстен чыга. Гомуми тилерүгә иярмичә, намусны саклап, кешелек дәрәҗәсен югалтмыйча яшәргә иде.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

БАЛА БЕР, ҺӨНӘР МЕҢ

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Кызларга – иҗат, егетләргә – спорт

Насретдиновлардагы хәл һәр гаиләдә дә күзәтелми, билгеле. Бөтен бала да вундеркинд түгел. Кайсылары укуын, гомумән, дәвам иттермәскә дә мөмкин. Кемдер, кызыл аттестатлы, медальле булып та, югары уку йорты турында хыялланмыйдыр да, бәлки. Һәм бу, заманасына күрә, табигый да! Акча да булсын, хезмәте дә авыр булмасын. Бу хакта бала гына түгел, кем дә хыялланадыр!

«Профилум» компаниясе оештырган сораштыруга күз салыйк. 7–9 сыйныф укучыларының кызыксынуларын өйрәнгән алар. Психологлар нәкъ шушы яшьтә баланың шәхес буларак формалашуын әйтә.

7–9 сыйныфларда укучы кызларга иҗади профессияләр кызыклы икән. Әйтик, биюче, җиһаз дизайнеры, веб-дизайнер, кондитер. Бу юнәлешне сораштыруда катнашучыларның 15 проценты сайлаган. 7 нче сыйныфта укучы кызларның кызыксынулары рәтенә тагын юриспруденция (6,1 процент), медицина (6 процент) керә. 8 нче сыйныфтагылар да күбрәк юриспруденция һәм менеджмент турында уйлый. 9 нчы сыйныфта бу исемлеккә IT тармак та килеп кушыла (4 процент).

Егетләргә килгәндә, алар өстенлекне спорт һәм IT юнәлешкә бирә икән. 7 нче сыйныфта укучы малайларның 15,2 һәм 17 проценты шушы тармакларны үз итүен әйткән. 8–9 нчы сыйныфта исә спорт белән кызыксыну кими башлый, алгы сафка IT индустрия чыга. Малайлар арасында автомеханик, эретеп ябыштыручы, пешекче кебек һөнәрләрне атаучылар да булган (якынча 5 проценты). Аеруча популяр һөнәрләр рәтендә исә – программист, тренер, эшмәкәр, спорт хөкемдары.

Югары уку йортына керергә ниятләгән 2023 елгы чыгарылыш укучыларыннан да сораштырганнар. Гадәттәгечә, медицина өлкәсе – хыялдагы һөнәрләрнең беренчесе. Аны сораштыруда катнашкан балаларның 25 проценты сайлаган. Гуманитар һәм социаль өлкә – икенче урында (18 процент). Аннан IT (16 процент), идарә һәм икътисад (12 процент), белем бирү (10 процент). Иминлек хезмәте һәм хәрби өлкәне сирәк сайлыйлар (3 процент). Спорт һәм хезмәт күрсәтү тармаклары да популяр түгел (2 һәм 1 процент).

«ТикТок»мы, вузмы?

Һөнәр сайлар алдыннан балаларга махсус тест узу, яшеренеп яткан сәләтләрен ачу, ярылып ятканнарын көчәйтү, кайсы тармакларга хирысрак булуын ачыклау өчен мөмкинлекләр җитәрлек хәзер. Кайбер ата-аналар балаларын махсус үзәкләргә алып килеп тикшертә дә. Түләүле хезмәт инде бу, билгеле.

Коуч, «Территория Мы» республика интеллектуаль-психологик лагере психологы, профориентация буенча белгеч Карина Вилдановадан һөнәрләр дөньясында ничек адашмаска икәнен, йөрәк белән акыл кушканны тыңлау файдасы турында сораштык. Ул да – үсмерләрнең «телим», «теләмим»нәрен өйрәнүче.

– Һөнәр сайлаганда күп факторлар исәпкә алына. Болар – баланың кызык-

Илдар Мөхәммәтҗанов

сынуы да, аның шөгыльләре дә, холкы, тормыш рәвеше, ата-анасының тәрбиясе дә. Миңа консультациягә килгәннәрдән ата-анасы, әби-бабасының кем булып эшләве турында да сорашам. Кайбер очракларда һөнәр буыннан-буынга тапшырыла торган була. Гаиләдә куелган таләпләр үсмернең сайлавына комачау итәргә йә, киресенчә, уйланырга мәҗбүр итәргә мөмкин. Иң мөһиме – баланың көчле якларын ачыклау. Моның өчен аның шәхес тибын, фикерләү рәвешен белергә кирәк, – ди Карина Вилданова.

Балаларының һөнәр сайлау этабы җиткәч, ата-аналарга тынычлык сакларга кирәк, дип киңәш итә белгеч.

– Еш кына ата-аналар һөнәри мөмкинлекләрне ачыкларга бик аз вакыт калгач киләләр. Ә мәктәптә балалардан имтихан тапшыра торган фәннәрне тизрәк сайлауларын таләп итәләр. Бу вакытта паника башланырга мөмкин, – ди ул. – Мәктәптә яратып укыган фән баланың киләчәген билгели дигән сүз түгел әле. Мәсәлән, ул химияне яхшы белә, ди. Әмма бу әле безнең каршыда булачак табиб яисә химик басып тора дигәнне аңлатмый бит. Шуңа күрә үсмернең психотибын һәм максатларын өйрәнү мөһим.

Карина Вилданова әйтүенчә, һөнәрләр дөньясы турында мөмкин кадәр иртәрәк сөйләшә башларга кирәк. Моны балачактан ук башлау хәерле. «Космонавт булам» дисәләр дә, канатларны кисәргә ашыкмыйк, юньле һөнәр түгел дип бәя бирмик. Ата-аналарга киңәш шул: профессия турында балалар белән берлектә фикер алышсыннар, фантазияне эшкә җиксеннәр. Иң мөһиме – ни өчен бу өлкәнең балада кызыксыну уятуын ачыкласыннар. Һөнәр турында ул кайдан белгән? Бу мәсьәләне тирәннән аңларга ярдәм итәчәк», – ди профориентолог.

Замана баласының хыяллары да заманча бит әле аның. Көннәрдән бер көнне үсмер: «Вуз кирәк түгел, «тиктокер» булам!» – дисә? Әти-әнигә бәгырь җимешенең мондый «һөнәр» сайлавын кабул итү җиңел бирелмәс бит?

– Социаль челтәрләр барыбызның да, шул исәптән үсеп килүче буынның да тормышына шактый үзгәрешләр кертте. Әлбәттә, «тиктокер» булам дигән сүзнең ата-анага аяз көндә яшендәй тәэсир итүе ихтимал. Нишләргә соң? Иң элек – тәнкыйтьләмәскә, баланың кызыксынуларын кимсетмәскә. «Юньле нәрсә түгел», «файдасыз шөгыль» дигән сүзләрдән качарга. Әлеге дә баягы сүз: бу өлкә аны нәрсәсе белән кызыктырган, җәлеп иткән? Дан казанумы? Иректә булумы? Җиңел акчамы? Асылда, үсмерләр бик акыллы, без аны аңлап бетермибез генә. Алар да бу дөньяда үз урынын эзли, – ди белгеч. – Әгәр дә бала ирек турында хыяллана икән, бу ирекне тагын кайдан алып буласын аңлатырга мөмкин. Аның бу ихтыяҗын тагын нинди һөнәрләр канәгатьләндерә ала. Акча турында хыяллана икән, сорау туа: тагын ничек акча эшләргә мөмкин? Ә бу акчаны ул нәрсә өчен тотарга җыена? Яшүсмергә аңлату кирәк. Әйтик, дан казанырга тели икән, бер мизгелдә бу хиснең юкка чыгуын дәлилләп була. Мәсәлән, интернет мәйданчыгы теләсә кайсы вакытта ябылырга мөмкин, ул чакта син нәрсә эшләячәксең, синең өстәмә «Б», «В», «Г» планы бармы? Ата-ананың һәм, белгечләр буларак, безнең бурыч – теге яки бу һөнәрнең кире ягын да күрсәтү, уңай якларын да, кимчелекләрен дә җиткерү. Һәрбер эштә дә бар алар. Иң мөһиме – «плюс»лар «минус»лардан артыграк булсын.

БЕЛГЕЧ СҮЗЕ

Практик психолог Зөһрә КӘРИМОВАның ата-ана һәм балага киңәшләре

➤Балага үзенең сайлавы өчен җаваплы булуын тоярга мөмкинлек тудырырга кирәк. Кем булырга тели, нәрсә турында хыяллана – иң элек шуларны белергә, үз фикереңне такмаска. Соңыннан ни өчен баланың шундый карарга килүен ачыкларга. Бала куркырга, шикләнергә дә мөмкин. Бу очракта аны нинди һөнәрләр илһамландыра, шул хакта белергә кирәк.

➤Еш кына ата-аналар үзләре булдыра алмаганны балаларыннан таләп итә. Һөнәрләр очрагында да шулай. Үз ихтыяҗларыгызны балаларыгыз бәрабәренә капларга тырышмагыз.

➤Күп кенә балалар инде хәзердән үк кем буласын хәл итә. Әмма үз фикерендә шикләнә. Бу очракта ата-анага баласына ышанырга гына кирәк. Бала әнә шул хисне эзли.

➤Ата-ананың бу җаваплы эштә роле – юнәлеш бирү, комачауламау.

➤«Нәселдә барысы да – укытучы, син дә укытучы буласың!» Мондый позициядән качарга киңәш итәм. Баланың «телим»нәре мөһимрәк.

➤Бала югары уку йортына барырга теләмәвен әйтергә мөмкин. Бу очракта ата-аналарга хисләр белән түгел, аек акыл белән эш итәргә, сәбәпләрен ачыкларга кирәк. Бала белән олылар позициясендә торып сөйләшү зарур.

Сер түгел, югары уку йорты дипломы булган, әмма хезмәт базарында урын таба алмаган белгечләр саны арта бара. Бер карасаң, бу норма саналган күренеш түгел. Әмма, Карина Вилданова әйтүенчә, хәзерге җәмгыятьтә «норма» төшенчәсе конкрет түгел.

– Мәктәптән соң – уку йортына, аны бетергәч, эш табарга һәм картайганчы шунда эшләргә дигән схемага күнеккән без. Әйе, әти-әниләребез, аларның әти-әниләре шулай яшәгән. Әмма тормыш үзгәрде. Бу яхшы да, начар да түгел. Хезмәт базарында үзгәрешләргә тизрәк күнегә алган, яңалыкны үзләштерә, тиз өйрәнә торган кешеләр ота. Хәзер эшкә дипломсыз да алырга мөмкиннәр. Әмма база белемнәр булырга тиеш. Хәзерге заманда синең фикерләү сәләтең, күнекмәләрең, эшеңнең нәтиҗәсе мөһимрәк. Әле моны аңлау авыр, әмма бу – чынбарлыгыбыз. Шунысын да онытмыйк: хәзер тормышыбызга ясалма интеллект кереп маташа. Кайбер хезмәткәрләрне алар да алмаштырырга бик мөмкин.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Балагызны нинди һөнәр иясе итеп күрергә телисез?

МАЛАЙЛАР	КЫЗЛАР
26% – IT белгеч	**11%** – IT белгеч
10% – МЧС, хәрби, көч структуралары вәкиле	**6%** – икътисад белгече
9% – медицина хезмәткәре	**5әр %** – спорт һәм юриспруденция юнәлешләре
7% – архитектура һәм төзелеш өлкәсендә	**4әр %** – төзелеш тармагы, МЧС, көч структуралары
4әр % – финанс юнәлешендә, нефть тармагында	**3%** – фән юнәлеше
3әр % – фән, спорт, юриспруденция юнәлешләре	**3әр %** – педагог, нефть-газ өлкәсе белгече
2% – сәясәт вәкиле	**2шәр %** – ветеринария, матурлык индустриясе, җитештерү тармагы
1әр % – педагогика, авыл хуҗалыгы, ветеринария, дин	**1әр %** – сәясәт, социаль өлкә һәм дин

SuperJob хезмәте мәгълүматлары буенча

Зөһрә САДЫЙКОВА

КАДЕРСЕЗ ЙОН

vk.com

Язга кергәч, авыл халкы башкарасы тагын бер мәшәкатьле һәм җаваплы эш бар. Ул да булса – сарык йонын алу. Бу эшне, гадәттә, өмә җыеп башкаралар. Дөрес, күпләр хәзер сарык асраудан читләште, чөнки йонының да, тиресенең дә кирәге юк, дип саныйлар. Бу чыннан да шулаймы? Илдәге соңгы вакыйгалар сарык үрчетүгә карашны үзгәртмәдеме? Әлеге малны асрауның файдасы бармы? Без шул хакта белештек.

Йон өчен түгел

«Татпотребсоюз» рәисе урынбасары Ренат Бикбов китергән мәгълүматлар буенча, республикадагы шәхси хуҗалыкларда 280 мең баш сарык асрала. Узган ел исә авылларда 310 мең баш сарык исәпләнгән. Саннар соңгы елларда сарык асраучыларның кимүен күрсәтсә дә, узган елның көзеннән аның йонына ихтыяҗ арткан.

«Татпотребсоюз» оешмасы ел саен халыктан 1492 тонна йон җыя. Агымдагы елда 173 тонна йон әзерләнгән. Бу – узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, 8 процентка күбрәк дигән сүз. Аның сүзләренчә, иң күп йонны республиканың Алексеевск, Кукмара, Баулы, Әгерҗе, Әлмәт, Әлки, Азнакай, Сарман, Зәй, Ютазы, Мамадыш һәм Мөслим районнарында әзерләтәләр.

– Яңа оешкан кооперативлар күрше районнарга чыгып җыялар. Егетләр халыктан үзләре барып ала. Тик тапшырган йон тигәнәктән чистартылган булырга тиеш. Республикадан җыелган йонны итек басу өчен кулланалар. Йон эрләүче апаларыбыз да бар. Узган көздән бирле районнар йонның бер өлешен аларга тапшыра иде. Зур шәһәрләрдә үткән язгы-көзге ярминкәләрдә сарык йонына сорау зур булды, – ди Ренат Бикбов.

Аның сүзләренчә, язгы йонның ак төстәгесен – 25 сумнан, карасын – 30, төслесен 20 сумнан алалар. Көзге йон исә кыйммәтрәк йөри. Ак төстәгесенә – 80 сум, карасына – 60 сум, тигәнәклесенә нибары 10 сум гына бирәләр. Язма әзерләгән вакытта без аралашкан кешеләрнең барысы да йоннарын нәкъ менә шул бәядән тапшыруларын әйттеләр. Күрәсең, 60–80 сумга йон тапшыру бик сирәкләргә генә эләгә торгандыр.

– Чыннан да, сарык йонының бәясе арзан, – диде Ренат Бикбов. – 2018 елдан бирле без аны 25 сумнан җыя башладык. Аңа кадәр ул 10 сум гына иде. Дәүләт йонның килограммына 30 сум биргәнлектән, без халыктан җыю хакын да күтәрә алдык. Йонның арзан булуының төп сәбәбе – аңа ихтыяҗ булмау. Йон эшкәртү, киез итек басу предприятиеләре ябылу да йогынты ясамый калмады. Йон юу фабрикасы да бетте. Аннан соң, халыкның кигән киеме дә үзгәрде. Күпчелегебез синтетикага күчте. Совет заманында армия өчен тун тегәләр иде. Сарыкның тиресе дә кирәк чаклар булды. Ул елларда сарык асрау отышлы иде. Элек халык йон белән бергә иттән дә табыш алса, хәзер итеннән генә бераз акча эшли ала. Гадәттә, Корбан бәйрәмнәренә саталар сарыкларны. Бер сарык сатып, кулга якынча 10 мең сум акча керә дигән сүз.

Мөслим районының Тамьян авылында яшәүче Айдар Шакиров та токымлы сарыкларны йон өчен түгел, ә ите өчен асрый.

– Хәзер сарыкны беркем дә йоны өчен асрамыйдыр инде, – ди ул. – Менә минем 700 баш сарыктан 1 тоннага якын йон чыга. Мин шуның килограммын 10 сумнан тапшырам. Элеккеге бәяләр булса, никадәрле табыш алган булыр идем. Ә хәзер бу турыда уйлау да көлке. Йонга ихтыяҗ юк бит, шунлыктан бәясе дә түбән. Тиресе дә чүпкә ыргытыла. Дөрес итеп файдаланганда менә дигән табигый чимал югыйсә. Халык чын йоннан синтетикага күчеп бетте. Ә менә курдюклы сарыкның итен яратып алалар, сораучылар күп, төшемле эш. Бер яшьлек сарыклар 20–25 кг ит бирә. Бер сарыктан 10–12 мең сум акча кертеп була дигән сүз. Шуңа күрә сарык асрау файдасыз, дип әйтә торган түгел. Төп табышны шуннан алабыз. Дөрес, үзебезнең тирәдә минем кебек токымлы сарык асраучыларны белмим, – ди ул.

Сарыкның файдасы булмаса да, зыяны юк. Арча районында яшәүче Гөлнур Ибраһимова әнә шулай ди. Көзге йонны итек басучылар алып китсә, язгысы шул килеш келәттә тора, ди ул.

– Йонны тетүчеләр юк хәзер. Тетүчесе булса, бәлки, йонны эрләп, оекбашлар бәйләр дә идек. Сарык итен үзебез бик сирәк ашыйбыз. Күбесенчә корбанга дип сатып алалар. Үзебезгә дип чалган вакытта бер өлешен авыз итәргә туры килә. Зур мал асрагач, күбесенчә шуның итен кулланабыз, – ди Гөлнур ханым.

Читнеке яхшырак

Сарык йонына ихтыяҗ бөтенләй юк, дип әйтеп булмый. Әйтик, киез итек басучылар үз республикабызда йон җитмәү сәбәпле, аны башка төбәкләрдән кайтартырга яки арадашчылар аша эшләргә мәҗбүр. Зур Кукмара авылында яшәүче Галимҗановлар гаиләсе итек басар өчен халыктан бары тик көзге йонны гына җыя. Аның өчен килограммына 30–45 сум бирәләр.

– Авылларда сарык асраучылар саны елдан-ел кими. Әле 3–4 ел элек кенә дә зур авыллардан 3–4әр көн йон җыя идек. Хәзер бу эш өчен нибары бер көн, кайвакыт хәтта 1 сәгать вакыт җитә. Булса, рәхәтләнеп җыяр идек югыйсә. Элеккеге елларда үзебездән артканын сата да идек. Хәзер үзебезгә дә җитми, – ди итек басу остасы Рәмзия Галимҗанова.

Халыктан җыелган йон җитмәгәч, күбесенчә сатып алырга туры килә, ди ул. Юылган Казахстан йонын да кайтарталар, йон тетүчеләрдән дә юнәтәләр. Боларыннан әзер йонны килограммын 230 сумнан сатып алалар. Алар исә Башкортстан, Ульяновск якларыннан кайтарта.

– Мәшәкате күбрәк булса да, халыктан җыеп, итек басарга үзең әзерләгән йонның сыйфаты яхшырак. Башка төбәкләрдән сатып алып тетелгән йонның сыйфаты һәрвакытта да канәгатьләнерлек булмый, – ди Рәмзия Галимҗанова.

Йон җыя торган оешма Казанда да бар. «Татвойлок» оешмасының генераль директоры Ринат Хөсәенов әйтүенчә, алар шәхси эшмәкәрләрдән йонның килограммын 25 сумнан сатып ала. Оешма киез, киез итекләр, киездән детальләр ясый.

– Эшмәкәрләр алып килгән йон гына җитми. Халыктан да кабул итәбез, тик алар да аз алып килә. Шуңа күрә башка төбәкләрдән дә сатып алырга туры килә, – ди ул. – Көзге йонны күбрәк итек басучылар алса, безгә язгы йонны китерәләр. Аның юылмаганын, сортларга бүленмәгәнен дә алабыз. Әмма ветеринар белешмәсе булырга тиеш.

Киңәш

✸Йон тәнегезгә никадәр якынрак булса, сәламәтлегегезгә шулкадәр файдалырак булыр.

✸Йон киемнәр – свитер, оекбаш, бияләйләрне мөмкин кадәр ешрак киегез.

✸Юрганнарның ясалма түгел, ә табигый йоннан сырылганын сайлагыз.

✸Йон белән эшләү мөмкинлегеннән баш тартмагыз: бәйләгез, киез басыгыз.

Файдасы бар

Кукмара районының Ташлы Елга авылында бертуган Назыйм һәм Назыйф Хәбибрахмановлар «Прекос» токымлы сарыклар үрчетү белән шөгыльләнә. Хәзерге вакытта хуҗалыкларындагы сарыклар 200 башка җиткән.

– Безнең сарыкларның йоннары югары сортлы булып санала. Озын һәм нечкә. Аны елына бер генә тапкыр – язын алабыз. Әлегә кыркый башламадык, бу эшне май урталарында башкарырга ниятлибез, – диде ул.

Фермер әйтүенчә, бер сарыктан 4–5 кг йон чыга. 200 баш терлектән якынча 1 тоннага якын йон алалар дигән сүз.

– Бу йоннан итек басып булмый. Аның каравы юрган, мендәр, башлыклар тегәләр, оекбашлар бәйлиләр. Үзебез дә тетеп әзерлибез. Андый йонга сорау зур. Бер елны, белдерү биргәннән соң, Сахалинга башлык бәйләргә алып киттеләр. Ләкин бу даими рәвештә түгел. Гадәттә, үзебезнекеләр килограммын 90 сумнан алып китә. Моннан тыш, йонны юып, мендәрләр дә ясаганыбыз булды. Туганыбыз юрган да сырды. Алар җиңел була. Киләчәктә, бәлки, үзебез дә юрганнар сырырбыз, мендәрләр тутырырбыз әле.

Назыйм Хәбибрахманов фикеренчә, йон хакы түбән булуның сәбәбе арадашчыларда да булуы бар.

– Алар, оятсызланып, 60 сум торганны 5 сумга да алып китәргә мөмкиннәр. Бүген авыл хуҗалыгында акча җитештерүче кулында түгел, ә арадашчы белән эшкәртүчедә. Без үзебез сарык йонын кыркырга махсус кешеләр чакырабыз. Бер сарык өстен алган өчен 150 сум акча түлибез. Йонын сатып, 360 сум акча кертәбез. Димәк, якынча 60 проценты үзебезгә кала. Бүген сарык түгел, хәтта сыер тотуның да файдасы юк. Сөт бәяләре төште, тирескә салым кертмәкче булалар, тикшерәләр. Болай булса, сыер да бетәчәк, – ди ул.

Шулай да, эшләгән эштән бары тик файда гына эзләргә кирәкми, дип саный фермер.

– Без сарыкчылык белән 10 ел шөгыльләнәбез. Башта авыр булды. Үзебезне танытканчы, ышаныч казанганчы берничә ел узды. Бүген, чыннан да, безнең сарыкларга сорау зур. Йоны да кирәк, ите тагын да кирәгрәк. Корбан бәйрәмнәренә, бәби чәйләренә күп алалар. Чөнки ите тәмле, исе юк. Авыл хуҗалыгында берничә тармакны алып барсаң гына отарга мөмкин. Бер елны берсе оттырса, икенчесенең отышлы булуы бар. Эштән файда гына да эзләмибез. Иң мөһиме – базарга сыйфатлы, хәләл һәм табигый продукт чыгару һәм эштән рәхәтлек кичерү. Менә анысы безнең хезмәттә тәгаен бар.

Укучы фикере

Сарык йонын азапланып алабыз, капчыкларга тутырып куябыз да келәткә кертеп әләбез. Сорап килгән кешеләрдән бәясен сорыйбыз да, арзан диеп, кире шунда кертәбез.

Идрис ГАЙНУЛЛИН

Кемгә кирәк, шуңа бушка бирәбез. Калганын чыгарып ташлыйбыз.

Гөлфия БИЛАЛОВА

Сарык йонын язып эрлибез дә, оекбаш бәйләп киябез. Кышын аяклар җылыда гына йөри.

Миңсылу ӘХМӘДИЕВА

Юып, юрган, матрас ясарга кирәк тә бит. Кеше ялкау хәзер.

Лениза МОСТАФИНА



САРЫК ЙОНЫН НИШЛӘТӘСЕЗ?

Сатабыз...............15,03%

Ташлыйбыз...............26,01%

Эрләп, оекбаш бәйлибез...............12,14%

Сарык асрамыйбыз...............46,82%

Газетаның «ВКонтакте» сәхифәсендә уздырылган сораштыру нәтиҗәсе

ТҮЛӘҮЛЕ НИКАХ

Озын гомерле никах өчен акча түли башларга мөмкиннәр. Халык мәнфәгатьләрен кайгыртучы депутатлар яңа закон проектын тәкъдим итеп маташа. Түләү гаилә булып 20 ел һәм аннан да күбрәк вакыт яшәгән парларга каралган. Гаилә бәхетен акча саклый алырмы? Гаилә нигезендә нәрсә ятарга тиеш?

kzn.ru

Асылы нидә?

Шушы көннәрдә ЛДПР партиясе депутаты Ярослав Нилов 20 ел һәм аннан да озаграк ел бергә яшәгән гаиләләргә акча түләү тәкъдиме белән чыкты. Парламентарий сүзләренчә, хәзерге демографик хәлебезне исәпкә алып, гаилә институтына ярыйсы гына ярдәм булыр иде.

– Тиздән Гаилә һәм тугрылык көне. Шуңа күрә озак вакыт гаилә корып яшәүчеләргә бәйле федераль тәкъдимне карау дөрес булыр иде. Әгәр дә парлар 20 елдан артык никахта торалар икән, һәркайсына 20 мең сум түлик. Биш ел саен шулай эшләргә кирәк. Шулай ук төбәкләр өстәмә рәвештә башка социаль ярдәм чараларын билгеләргә хокуклы булачак, – дип тәкъдим итә Ярослав Нилов.

Акча түләүне бәллүр туйдан башларга кирәк дип саный депутат. Ягъни 15 ел бергә яшәүчеләрдән. Бу очракта аларга 15 мең сум бирергә тәкъдим ителә.

Ярослав Нилов әлеге закон проектын ЛДПР партиясенә нигез салучы Владимир Жириновскийга багышларга теләүләрен дә җиткергән. ЛДПР лидерының гаилә стажы шактый зур булганы билгеле.

Шатлыкта да, кайгыда да

Фидания һәм Ләбиб Леронналарның гаилә стажы – 41 ел. Депутатлар тәкъдиме тормышка ашса, аларга да озын гомерле никах өчен акча түләргә тиешләр, димәк. Гаилә учагын саклаучы Фидания ханымнан бу тәкъдимгә карата нинди фикердә булуын сорадык.

– Мондый тәкъдим турында нәрсә әйтим? Өзелер дәрәҗәгә җиткән никахны бу гына туктатмас, билгеле. Икенче яктан караганда, хәзер акчаны беренче урынга куя торган буын үсеп җитте. Бәлки, алар өчен бу күпмедер дәрәҗәдә стимул да булыр. Гаилә тормышы тоташ чәчәктән һәм шатлыктан гына тормый, авырлыгы да килә, тормыш сабырлыкны сынап кына тора, – диде ул. – Шуңа күрә бу тәкъдимне, бәлки, дәүләт тарафыннан гаиләгә игътибар арту, дип аңларга кирәктер. Әлләничә еллар бергәләп шатлык-сөенечләрен дә, авырлыкларын да бергә кичкән әби-бабайларны беләм. Көннәрдән беркөнне аларга акчалата бүләк бирелә икән, моңа шатланырга гына кирәк! Пенсияләр зур түгел, бер ярдәм булыр иде.

Ел	Гаилә коручылар	Аерылышучылар	Аерма
1960	1499581	184398	+713%
1970	1319227	396589	+232%
1980	1464579	580720	+152%
1990	1319928	559918	+135%
1995	1075219	665904	+61%
2000	897327	627703	+42%
2005	1066366	604942	+76%
2010	1215066	639321	+90%
2015	1161068	611646	+89%
2020	770857	564704	+36%

Россия буенча мәгълүмат

Фидания ханым фикеренчә, тормыш авырлыгын ялгызы күтәргәннәрне, балаларын сыңар канат булып тәрбияләп үстергәннәрне дә онытмаска кирәк. «Алар өчен дә файдалы булган акыллы тәкъдим кертсеннәр иде», – ди ул.

Саба районындагы Явлаштау авылында гомер итүче Рәзинә һәм Илшат Галимҗановлар 29 ел бергә. Кем әйтмешли, тәҗрибәсез түгелләр. Өч балага гомер биргәннәр, хәзер менә Рәзинә ханым – үзе дә каенана. Хөкүмәт бирә торган акчага бишкуллап риза булыр идек, ди.

– Хәзерге вакыт белән элеккесен – без тормыш корган чакларны чагыштырсаң, җир белән күк арасы инде. Элек акча юк иде, колхоз акча түләмәде. Ничек яшәгәндер, белмим! Хәзер исә акча күпме булса да җитми. Капканың теге ягына чыксаң да, акча кирәк. Булган кадәренең бәрәкәте булсын, дибез, – ди хуҗабикә. – Хөкүмәт, шундый тәкъдимне тормышка ашырып, акча бирсә, без риза. Хәзер бәби тапканга да акча бирәләр. Безнең чорда декрет акчасы да булмады. Минем соңгы балама гына декрет акчасы чыкты. Инде шул 20 елдан артык торган өчен түләү булса, начар түгел.

Рәзинә апаның яңа гаилә корганнарга киңәше дә бар:

– Кавышканнар икән, торсыннар. Бер-берсен хөрмәт итеп яшәсеннәр. Аңлашырга, санлашырга кирәк. Хәзер яшьләрне уйлыйбыз бит инде. Рәхәтләнеп яши торган булсыннар иде! – ди ул.

Өйләнгәндә җырлыйлар, ә өйләнгәч?

Акча белән кызыктырып кына гаилә институтын саклап калу мөмкинме? 20 ел түгел, 1 елын да яши алмаган парларны аерылышуга нәрсә этәрә? Гаилә нигезен нытыгта тагын нәрсәләр стимул була алыр иде? Әлеге сорауларга җавапны психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева белән эзләдек.

Психолог сүзләренчә, акча түләү кебек тәкъдимнәр гаиләләрне сакларга азмы-күпме ярдәм итәргә мөмкин. «Дөресрәге, гаиләне саклап калырга бер сәбәп була ала. Бигрәк тә матди яктан ярдәм көткәннәргә, акчаны мотивация итеп күргәннәргә. Психолог буларак, мөнәсәбәтләрнә нокта куярга теләүче парлар белән еш очрашырга туры килә. Акча ягын гына түгел, парларның психологик халәтенә бәйле тәкъдим турында да уйлансыннар иде», – ди белгеч.

Аерылышуларның сәбәпләренә килгәндә, биредә дә әлеге дә баягы акча мәсьәләсе кабыргасы белән килеп баса. «Яшьләр матди яктан өлгермичә өйләнешә дә аерылыша. Кредит, бурычлар, ата-аналар, туганнар белән бергә яшәү – болар барысы да аерылышуга китерергә мөмкин», – ди белгеч.

Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева сүзләренчә, көндәлек мәшәкатьләр белән очрашу да – парларның мөнәсәбәтләре өчен сынау. «Төшенкелек, кәефсезләнү, апатия ише хисләргә бирелергә мөмкин. Депрессиягә кадәр үк барып җитү дә ихтимал», – ди ул.

Араларны суыта торган тагын бер сәбәп – ике арада хөрмәт хисе булмау.

– Бер-береңне ишетә һәм тыңлый белмәү, юл куймау – төп сәбәпләрнең берсе. Миңа гаиләләр дә әнә шул сәбәп белән еш килә. Тагын берсе – бер-береңнән канәгать булмау, гел тәнкыйтьләп тору. Ягъни пардагының берсе икенчесен башта бик идеальләштерә. Бергә яши башлагач, ал «күзлек»не салырга туры килә. Чынбарлык син теләгәнчә булмаска да мөмкин. Сәбәпләрне ачыклау, үз-үзең белән эшләү урынына мөнәсәбәтләргә нокта кую юлын сайлыйлар, – дип аңлатты психолог.

Гаилә төшенчәсенә карата ике кешенең ике төрле караштa булуы да тормышта киенлыклар тудыра. Мәсәлән, хатын карьера турында хыяллана, ди, ә ир-ат аның өйдә утыруын тели. Яисә ике кешенең бала тәрбияләүгә карашы ике төрле булырга мөмкин.

Аерылышуга илтә торган сәбәпләр арасында хыянәт, тормыш сынаулары, психологик басым ясау (абьюз мөнәсәбәтләр), психологик тайпылышлар (наркомания, хәмергә бәйлелек, комарлы уеннар) да бар.

Психолог әйтүенчә (аның җавапларыннан да чамаларга була), хәзерге заманда гаиләләрнең таркалуына ике кешенең психологик яктан тормышка әзерлексез булуы китерә. «Шәхес буларак, кешеләр үз өстенә җаваплылык алудан курка. Хәзер күпчелек үзе турында, үз максатлары турында гына уйлый. «Мин» беренче урында. Ә гаиләдә үзең турында гына уйламыйсың бит. Күпләр проблемадан кача. Бу «бала позициясе» дип атала. Ягъни, «нишләп әле мин моны хәл итәргә тиеш» дип, мәшәкатьтән чыгу юлын эзләп тормый», – ди ул.

Гаиләне саклап калырга тагын нәрсәләр ярдәм итә ала соң?

– Хакимият акчалата ярдәм чаралары турында даими кайгыртып тора анысы. Минемчә, социаль проектларга да күбрәк игътибар бирсеннәр иде. Шулай ук психологик ярдәм турында да онытмаска иде. Әйткәнемчә, низаглар, аңлашылмаучанлыклар белән очрашкан парлар мәсьәләне хәл итү юлын аерылышуда гына күрә. Алар белән эшләргә кирәк. Мактанып әйтү түгел, үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм: берничә гаиләне таркалудан саклап калганым бар. Психологик терапия, проблеманың сәбәпләрен ачыклау бәрабәренә бу. Җәмгыятьтә сыйфатлы ярдәм күрсәтерлек белгечләр күп булсын иде. Яшь парларга яши башлаган чорда ярдәм аеруча кирәк бит. Гаилә ул – команда. Аларга менә шуны җиткерергә кирәк, – диган фикердә белгеч.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ФИКЕР

Сәйдә абыстай АППАКОВА:

– Гаиләдә аңлашылмаучылык чыккан, үпкәләшкән саен өйдән чыгып китмиләр, әти-әнигә барып зарланмыйлар. Алар инде үз вазыйфаларын тулысынча үтәгән: сине үстергән, тәрбияләгән, хәер-фатихасын биреп, никахын укыткан, туен ясаган. Ә син аларны кайгыга саласың, ике арадагы гаилә мөнәсәбәтләрен, ир белән хатын арасындагы аңлашылмаучылыкка аларны да өстерисең. Кемгә җиңел моннан? Ике кеше тыныч кына уздырып җибәрерлек үпкәне дүрт кеше тикшерә. Ир белән яшисең, гаиләле буласың килгән икән, юкка-барга чәчрәмә, җаен тап, акыл белән эш ит. Рус халык мәкалендәгечә: «Таудан чана шуасың килгән икән, чанасын таугa үзең тартып мен». Шул чагында гына тирләп-пешеп чана шуунының ләззәте була.

ГАМӘЛДӘГЕ ТӨП ЯРДӘМ ЧАРАЛАРЫ

БАЛАЛАРГА БЕРДӘМ ПОСОБИЕ

Йөкле хатын-кызлар һәм 17 яшькә кадәрге балалы гаиләләр өчен пособие яшәү минимумыннан кимрәк керемле гаиләләргә бирелә. Тагын бер шарты: балалар һәм аларның ата-аналары, Россия гражданлыгына ия булып, безнең илдә яшәргә тиеш. Түләү билгеләнгәндә, гаиләнең керемнәре һәм милке, шулай ук ата-ананың мәшгульлеге исәпкә алына. Бердәм пособие социаль ярдәмнең инде гамәлдәге берничә чарасын берләштерә: беренче атналарда учетка баскан йөкле хатыннарга айлык пособие; вакытлыча эшкә сәләтсез булган очракта һәм ана булу сәбәпле, мәҗбүри социаль иминләштерелергә тиеш булмаган гражданнарга бала карау буенча пособие; 3 яшькә кадәр, 3 яшьтән 7 яшькә кадәр һәм 8 яшьтән 17 яшькәчә булган балаларга айлык түләүләр.

АНА КАПИТАЛЫ

2023 елда беренче бала туганда ата-аналар 589,5 мең сум алачак, бу 2022 елга караганда 65 мең сумга артыграк. Әгәр гаиләдә икенче бала туса, ана капиталы суммасы 779 мең сумны тәшкил итәчәк. Ләкин гаилә беренче балага сертификат алган булса, бу очракта дәүләт ярдәме күләме 189,5 мең сум булачак, бу 2022 елга караганда 20,9 меңгә күбрәк.

БАЛА ТУГАЧ БИРЕЛӘ ТОРГАН ПОСОБИЕ

2023 елда бала туганда бер тапкыр бирелә торган пособие 23011 сумны тәшкил итә.

ИПОТЕКА

Россиядә күпбалалы гаиләләргә ярдәм итү программасы гамәлдә, аның нигезендә дәүләт ипотека кредитын тулысынча яки өлешчә түләүгә 450 мең сумга кадәр акча бүлеп бирә. Мондый ярдәмгә өченче яисә аннан соңгы баласы 2019 елның 1 гыйнварыннан соң туган гаиләләр хокуклы.

8 май | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
20.45 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00 «Манзара 16+
08.00 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «ОТЕЦ СОЛДАТА» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00 М.Мәһдиев.«БЕЗ – КЫРЫК БЕРЕНЧЕ ЕЛ БАЛАЛАРЫ». Телевизион фильм 12+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 16+
14.30 «Соотечественники». Муса Гареев. Дважды герой 16+
15.00 «Негромкие песни Великой войны» 6+
15.30 З.Зәйнуллин. «41НЕҢ АРБАЛЫ ХАТЫННАРЫ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». Муса Җәлил 16+
18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
19.00, 00.40 «Таяну ноктасы» 16+
19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар». Гази Заһитов 16+
22.10 «ВОЕННО-ПОЛЕВОЙ РОМАН» 16+
00.00 «Каравай». Национальные куклы 6+
00.25 «Рыцари вечности» 16+
01.05 «Ком сәгате» 16+
02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 16+
04.45 «Җырлыйк әле!» 12+
05.35 «Оныта алмыйм...» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Мәңгелек юлында». Мөхәммәт Мирзаның 70 яшьлек юбилей кичәсе 12+
10.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.30 «Туган җир» 12+
12.05 Г.Кариев. «АРТИСТ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
15.00 «Әдәби хәзинә». Габдулла Кариев 6+
15.30 Р.Харис. «КҮЗЛӘРЕҢНӘН ҮБЕП». С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле 16+
17.10 «Сугыш чоры җырлары» 6+
18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
18.20 «Габдрахман». Документаль фильм 16+
19.20 «Калеб» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.30 «Заман көзгесе» 6+
21.25 З.Зәйнуллин. «41НЕҢ АРБАЛЫ ХАТЫННАРЫ». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле 16+
23.45 «Сугыш чоры җырлары» 6+
00.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 16+
00.40 «Сугыш чоры җырлары» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
04.15 «Башваткыч» 12+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш...» (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ
06.00 Новости
06.10 Фильм «ГОРЯЧИЙ СНЕГ» 12+
08.10 Фильм «ЛЕТЯТ ЖУРАВЛИ» 12+
10.00 Новости (с субтитрами)
10.15 Фильм «НА ВОЙНЕ КАК НА ВОЙНЕ» 12+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 «ВСТРЕЧИ НА ЭЛЬБЕ» 12+
13.10 Киноэпопея Юрия Озерова. «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «НАПРАВЛЕНИЕ ГЛАВНОГО УДАРА» (S) 12+
15.35 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «БИТВА ЗА БЕРЛИН» (S) 12+
17.05 «ОСВОБОЖДЕНИЕ». «ПОСЛЕДНИЙ ШТУРМ» (S) 12+
18.30 Премьера. Праздничный концерт ко Дню Победы в Кремле «СПАСИБО ЗА ВЕРНОСТЬ, ПОТОМКИ!» (S) 12+
21.00 «Время»
21.35 Фильм «КРАСНЫЙ ПРИЗРАК» (S) 16+
23.30 Фильм «УРОКИ ФАРСИ» (S) 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
03.35 ПОДКАСТ.ЛАБ «Кольцо Милорадовича» 16+
04.10 ПОДКАСТ.ЛАБ «Произвольная программа» 16+

1 РОССИЯ 1
05.30 Мария Куликова, Глафира Тарханова, Константин Соловьёв, Сергей Юшкевич. «С ПРИВЕТОМ, КОЗАНОСТРА» 16+
07.10 Карина Андоленко, Анатолий Руденко, Лариса Лужина, Татьяна Агафонова, Евгений Леонов-Гладышев, Галина Бокашевская. «ДОЖДАТЬСЯ ЛЮБВИ» 12+
11.00, 17.00, 20.00 Вести
11.50 Премьера. «Малая земля. Герои без ретуши». Фильм Алексея Денисова 12+
12.40 Ксения Гусева, Сергей Горобченко, Николай Добрынин, Андрей Казаков, Вячеслав Разбегаев, Арина Постникова, Лариса Домаскина, Илья Ильиных, Константин Белошапка. «ПЕРЕКАТИ-ПОЛЕ» 16+
17.50 Виктор Добронравов, Владимир Ильин, Валерия Федорович, Евгения Дмитриева, Игорь Хрипунов, Павел Майков, Владимир Симонов и Ян Цапник в фильме «ПАЛЬМА» 6+
20.45 Местное время. Вести-Татарстан
21.00 Премьера. Ольга Арнтгольц и Сергей Перегудов в фильме «ФАМИЛЬНОЕ ГНЕЗДО» 12+
00.30 Юлия Подозерова, Анастасия Акатова, Нил Кропалов, Дмитрий Муляр, Владислав Шкляев. «ПРЕКРАСНЫЕ СОЗДАНИЯ» 12+

МАТЧ! МАТЧ ТВ
06.00 «Динамо». Ленинград». Документальный фильм 12+
07.00, 10.00, 14.25, 17.35, 20.55 Новости
07.05, 13.40, 17.00, 22.05 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 Бокс. Чемпионат мира. Мужчины. Трансляция из Узбекистана 0+
10.55 Художественная гимнастика. Кубок сильнейших. Прямая трансляция из Москвы
14.30 Баскетбол. Единая лига ВТБ. Финал. Прямая трансляция
17.40 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Женщины. Финал. «Локомотив» (Калининградская область) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
19.55 «Внуки победы». Документальный цикл 12+
21.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
22.55 Профессиональный бокс. Нокауты 16+
00.55 Смешанные единоборства. UFC. Алджэмейн Стерлинг против Генри Сехудо. Трансляция из США 16+
01.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Коринтианс» – «Форталеза». Прямая трансляция
04.00 Хоккей. Международный турнир. Россия – Белоруссия. Трансляция из Казахстана 0+

НТВ
04.40 «Алтарь Победы» 0+
05.35, 08.20 Аристарх Ливанов. «ДЕД МОРОЗОВ» (S) 16+
08.00, 10.00, 16.00, 19.00 «Сегодня»
10.20 Михаил Евланов, Татьяна Казючиц, Аристарх Ливанов. «МАМКИНА ЗВЕЗДОЧКА» (S) 16+
14.35, 16.20 Сергей Пускепалис, Федор Добронравов, Роман Мадянов, Юрий Стоянов. «БЕССМЕРТНЫЕ» (S) 12+
17.00 Премьера. Владимир Веревочкин, Михаил Евланов, Алексей Шевченков. «ПОЗЫВНОЙ «ЖУРАВЛИ» (S) 16+
19.35 Премьера. Фильм «ПОЗЫВНОЙ «ЖУРАВЛИ» (S) 16+
22.20 Премьера. «SHAMAN. Я русский» (S) 16+
00.15 «Захар Прилепин. Уроки русского» 12+
00.40 «ОСНОВАНО НА РЕАЛЬНЫХ СОБЫТИЯХ». «НЮРНБЕРГ 1946» 16+
03.40 «Алтарь Победы» 0+

ДОМАШНИЙ
06.30 «ТАНЦОР ДИСКО» 16+
09.15 «ТАНЦУЙ, ТАНЦУЙ» 16+
12.20 «СЕРДЦЕ ЖЕНЩИНЫ» 16+
14.30 «АНГЕЛ В СЕРДЦЕ» 16+
19.00 «ЖЕНА С ТОГО СВЕТА» 16+
23.05 «ТАНЦОР ДИСКО» 16+
01.45 «ЧУЖАЯ ДОЧЬ». 5-я – 8-я серии 16+
04.50 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
05.40 «6 кадров» 16+
06.00 «ОПАСНЫЙ КРУИЗ» 16+

ЗВЕЗДА
05.35, 08.15 «Диверсанты». Докудрама. 1-я – 4-я серии 16+
08.00, 13.00, 18.00 Новости дня 16+
09.35, 13.15, 18.20 «РАЗВЕДЧИКИ». Телесериал. Фильмы 1-й и 2-й 16+
21.00 «Легендарные матчи» 12+
00.00 «История военных парадов на Красной площади». Документальный сериал 16+
02.35 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». Телесериал. 1-я – 3-я серии 12+

9 май | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН
21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
06.00, 07.10 «Манзара» 16+
07.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 22.00 Новости Татарстана 16+
08.10 «Здравствуйте!» 16+
09.00 «Сугыш чоры җырлары» 12+
09.45 Торжественное прохождение войск Казанского гарнизона, посвященное 78-ой годовщине Великой Победы 0+
11.00 Р.Харис. «КҮЗЛӘРЕҢНӘН ҮБЕП...» С.Өметбаев исемендәге Минзәлә татар дәүләт драма театры спектакле 12+
12.40 «ТАНКИ» 12+
14.45 «Йөрәкләрдә һаман ут яна...» Концерт 6+
16.30 «Татарлар» 12+
17.00 «Габдрахман». Док. фильм 12+
18.00 Спецвыпуск 12+
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания» 0+
19.00 «ZV-2». Документальный фильм ко дню Победы из зоны СВО 16+
20.00, 21.00 Праздничный концерт 0+
22.30 «ГЛАВНЫЙ КОНСТРУКТОР» 12+
00.50 «Видеоспорт» 16+
01.15 «Соотечественники». Муса Гареев. Дважды герой 16+
01.40 «Вехи истории». Их подвиг бессмертен 16+
02.05 «Манзара» 16+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА
06.00, 13.05, 01.05 «Манзара» 16+
08.00 «Батырларга хат. Письма героям» 6+
09.45 Казан гарнизонының Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган тантаналы узышы 6+
11.00 М.Мәһдиев. «Без – 41 ел балалары» 6+
12.05 Ике тапкыр Советлар Союзы Герое Муса Гәрәев турында телеочерк 16+
15.00 «Йөрәкләрдә һаман ут яна...» Концерт 6+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
18.00, 22.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
18.25 «Ватандашлар». Гази Заһитов. Исемсез батырлык 6+
18.55 Фашизмга каршы сугышта һәлак булганнарның якты истәлегенә... Бер минутлык тынлык 6+
19.01 «Сугыш чоры җырлары» 6+
20.00 Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 78 еллыгына багышланган бәйрәм концерты 6+
22.25 Т.Миңнуллин. «НӘЗЕР». М.Фәйзи исемендәге Оренбург татар дәүләт драма театры спектакле 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
02.50 «Караоке татарча» 12+

1 КАНАЛ
05.00 Новости
05.10 «День Победы». Праздничный канал
09.50 Новости
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы (S)
10.40 Новости (с субтитрами)
11.30 «ДИВЕРСАНТ. КРЫМ» (S) 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.20 «ДИВЕРСАНТ. ИДЕАЛЬНЫЙ ШТУРМ» (S) 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.25 «ДИВЕРСАНТ. ИДЕАЛЬНЫЙ ШТУРМ» (S) 16+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.00 «ДИВЕРСАНТ. ИДЕАЛЬНЫЙ ШТУРМ» (S) 16+
19.25 Премьера. Фильм «1941. КРЫЛЬЯ НАД БЕРЛИНОМ» (S) 12+
21.00 «Время»
22.00 Легендарное кино в цвете. «В БОЙ ИДУТ ОДНИ «СТАРИКИ» 12+
23.30 «БЕЛОРУССКИЙ ВОКЗАЛ» 0+
01.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
01.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Жизнь замечательных» 16+
02.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
03.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Пусть не говорят, пусть читают» 16+
04.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Гайдай 100» 12+

1 РОССИЯ 1
04.20 «ЧЕРЕЗ ПРИЦЕЛ» 12+
08.00 «День Победы». Праздничный канал
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвящённый Дню Победы
10.40, 17.00, 20.00, 21.20 Вести
12.05 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню Победы
13.45 «Т-34» 12+
17.45 Премьера. «Песни от всей души» в День Победы 12+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.00 Премьера. «Песни от всей души» в День Победы 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
22.10 «КАТЮША» 12+
23.50 «ПЕРВЫЙ ОСКАР» 12+
01.50 «ПРЫЖОК БОГОМОЛА» 12+

МАТЧ! МАТЧ ТВ
06.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
07.00, 10.00, 14.50, 16.50, 20.50 Новости
07.05, 14.20, 16.55, 20.55, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
10.05 «Страна героев. Николай Королёв» 12+
10.25 Бокс. Чемпионат мира. Мужчины. Трансляция из Узбекистана 0+
11.30 «ОМСБОН. История одной жизни». Документальный фильм 12+
11.55 Хоккей. Лига Ставок Большой тур Сборной. Россия – Белоруссия. Прямая трансляция из Красноярска
14.55 Гандбол. Чемпионат России. OLIMPBET Суперлига. Мужчины. 1/4 финала. «Чеховские медведи» (Московская область) – «СГАУ-Саратов». Прямая трансляция
16.30 «Бессмертный футбол». Специальный репортаж 12+
17.30, 19.05 Волейбол. Чемпионат России. Pari Суперлига. Мужчины. Финал. «Динамо» (Москва) – «Зенит-Казань». Прямая трансляция
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма». Минута молчания
20.00 «Внуки победы» 12+
21.40 Футбол. Лига чемпионов. 1/2 финала. «Реал» (Мадрид, Испания) – «Манчестер Сити» (Англия). Прямая трансляция
00.55 Художественная гимнастика. Гала-концерт. Трансляция из Москвы 0+
01.55 Пляжный волейбол. Чемпионат России. Женщины. Финал. Трансляция из Анапы 0+
02.55 Новости 0+
03.00 «География спорта. Воронеж» 12+
03.25 Американский футбол. Чемпионат России. «Патриоты» (Москва) – «Грифоны» (Санкт-Петербург) 0+
05.30 «Правила игры» 12+

НТВ
04.25 Военная драма «ДВАДЦАТЬ ВОСЕМЬ ПАНФИЛОВЦЕВ» (S) 12+
06.00, 08.15 Фильм «ДЕД МОРОЗОВ. ОРУЖИЕ ВОЗМЕЗДИЯ» (S) 16+
08.00, 09.45, 10.40, 16.00, 19.00 «Сегодня»
10.00 Москва. Красная площадь. Парад, посвященный Дню Победы
11.00 «НЮРНБЕРГ» (S) 12+
13.00 «ТОПОР» (S) 16+
14.35 «ТОПОР. 1943» (S) 16+
16.30 «ТОПОР. 1943» (продолжение) (S) 16+
16.50 «ТОПОР. 1944» (S) 16+
18.20 «В АВГУСТЕ 44-ГО...» 16+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.35 Фильм «В АВГУСТЕ 44-ГО...» (продолжение) 16+
20.50 Премьера. Андрей Смоляков в военном фильме «ТОПОР 1945. КЕНИГСБЕРГ» (S) 16+
22.40 Андрей Фролов, Юлия Афанасьева. «ДИНА И ДОБЕРМАН» (S) 16+
02.00 «У АНГЕЛА АНГИНА» (S) 16+
03.30 «СЕМЬ ПАР НЕЧИСТЫХ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ
06.30 «ОПАСНЫЙ КРУИЗ» 16+
07.35 «ЛЮБОВЬ ЗЕМНАЯ» 16+
09.30 «СУДЬБА» 16+
12.45 «КЕМ МЫ НЕ СТАНЕМ» 16+
14.45 «ЖЕНА С ТОГО СВЕТА» 16+
18.55 «Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания»
19.00 «ИЗ СИБИРИ С ЛЮБОВЬЮ» 16+
22.40 «ТАНЦУЙ, ТАНЦУЙ» 16+
01.30 «Свидание с войной» 16+
04.40 «Знать будущее. Жизнь после Ванги» 16+
06.15 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА
06.05 «ВАРИАНТ «ОМЕГА». Телесериал. 4-я и 5-я серии 12+
09.00, 18.00 Новости дня 16+
10.00 Москва. Красная площадь. Военный парад, посвященный 78-й годовщине Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 гг..
11.10 «Бомбардировщики и штурмовики Второй мировой войны». Документальный сериал 16+
13.55 «Стрелковое оружие Второй мировой». Документальный фильм 16+
15.20 «Танки Второй мировой войны». Документальный фильм 16+
16.45 «Девять героев» 12+
18.55 Светлой памяти павших в борьбе против фашизма. Минута молчания
19.05 «Освобождение» 16+
20.00 «ДНЕВНИКИ ПАМЯТИ»
22.00 «ДОРОГА НА БЕРЛИН» 16+
23.25 «ЖИВЫЕ И МЕРТВЫЕ» 12+
02.45 «Калашников» 12+
03.25 «ФРОНТ». Телесериал. 1-я и 2-я серии 16+

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан юридик институты» федераль дәүләт казна югары белем бирү мәгариф учреждениесе башлыгы, полиция генерал-майоры **Зиннуров** Фоат Кәнәфи улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

* * *

Республикада физик культураны һәм спортны үстерүгә зур өлеш кертүләре, күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен «Спортны үстерү үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе спортчы-инструкторы (Чаллы шәһәре) **Галкина-Сәмитова** Гөлнара Искәндәр кызы, Татарстан Республикасының «Тхэквондо федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты **Мусин** Рафис Габсәләм улы, Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы шәхси состав белән эшләү идарәсенең һөнәри әзерлек бүлеге баш белгече-эксперты **Мөхетдинов** Фәнил Фәрит улы, «Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы спорт корылмаларын эксплуатацияләү бүлеге башлыгы **Фазылҗанов** Равил Илтөзәр улы **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

* * *

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре һәм 1941–1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүгә зур өлеш кертүләре өчен Бөек Ватан сугышында катнашучы **Ванюков** Илья Васильевич, Бөек Ватан сугышында катнашучы **Левагин** Николай Васильевич, тыл хезмәтчәне **Усцова** Александра Дмитриевна, Бөек Ватан сугышында катнашучы **Хәкимов** Равил Гыйният улы, тыл хезмәтчәне **Хөсәенова** Халидә Мифтах кызы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

* * *

«Галиәсгар Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры» дәүләт бюджет учреждениесе драма артисты **Җиһаншин** Фәнис Рәдиф улына **«Татарстан Республикасының халык артисты»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе Дәүләт янгынга каршы көрәшү хезмәте янгынга каршы көрәшү федераль хезмәтенең янгын сүндерү-коткару отряды 7 нче янгын сүндерү хезмәте янгынга каршы көрәшү элемтә үзәк пункты элемтә мастеры, отставкадагы эчке хезмәт полковнигы **Мамаков** Олег Григорьевичка, Россия Федерациясе Граждан оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигать бәла-казаларының нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсе күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе башлыгы урынбасары – күзәтчелек һәм профилактика чараларын оештыру бүлеге башлыгы, эчке хезмәт полковнигы **Маринин** Олег Владимировичка, «Татарстан Республикасының Янгыннан саклану хезмәте» Татарстан Республикасы дәүләт казна учреждениесенең Түбән Кама янгынга каршы көрәшү отряды башлыгы **Насыйров** Илсур Нурулла улына **«Татарстан Республикасының атказанган коткаручысы»** дигән мактаулы исем бирелде.

* * *

«Татарстан Республикасы «Динамо» физкультура-спорт җәмгыяте» иҗтимагый-дәүләт оешмасы әгъзалары: Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе 6 номерлы «Савиново» полиция бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлегенең полиция участок уполномоченные, полиция майоры **Водяшев** Эдуард Анатольевичка, Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Казан шәһәре буенча идарәсе тикшерү идарәсенең 3 номерлы «Зареченский» полиция бүлеге тарафыннан хезмәт күрсәтелә торган территориядәге җинаятьләрне тикшерү бүлегенең милеккә каршы җинаятьләрне тикшерү бүлекчәсе тикшерүчесе, юстиция подполковнигы **Дементьев** Евгений Александровичка **«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ҖӘРӘХӘТСЕЗ УЗСЫН

Бәла аяк астында, дибез. Кызганыч, җәйге чорда бу сүзләрнең хаклыгына аеруча еш инанырга туры килә. Рәсми саннарга күз салсак, ел дәвамында күзәтелгән барлык имгәнү-җәрәхәтләнүләрнең төп өлеше нәкъ менә шушы чорда теркәлә. Шуңа күрә бүгенге сәхифәбездә җәй көне бәлагә тарыган кешегә беренче ярдәм күрсәтү кагыйдәләрен искә төшерергә булдык.

vk.com

Сөяк сыну

Иң элек сынган урынга кул астындагы таяк, такта яки эре ботаклар ярдәмендә шин салыгыз. Җәрәхәтләнгән очлык мөмкин кадәр азрак хәрәкәтләнерлек булсын. Аннары сынган кул-аякны, яулык, шарф, каеш ярдәмендә, шин ике янәшә буынны эләктерерлек итеп бәйләгез. Әйтик, балтыр сөякләре сынса, шинны тез һәм балтыр-табан буыннары эләгерлек итеп салырга кирәк. Болай эшләгәндә алар хәрәкәтсез булачак, сөяк сыныклары, урыннарыннан күчеп, тирәяктагы тукымаларны җәрәхәтли алмаячак. Ботка шин салганда, аеруча игътибарлы булырга кирәк. Әгәр якын-тирәдә шинга аз гына булса да охшаган бернәрсә дә юк икән, җәрәхәтләнгән аякны бинт ярдәмендә сәламәт аякка бәйләп куегыз. Иңбаш сөяге сынган вакытта кулны гәүдәгә бәйләп кую киңәш ителә. Шуннан соң гына зыян күрүчене, машинага утыртып, хастаханәгә озатырга мөмкин.

Бәрелү

Башта бәрелгән урынга кысып торучы бәйләвеч салып, аны боз, салкын компресс, юеш тастымал, салкын металл әйбер ярдәмендә суытырга кирәк. Алга таба бәрелгән аяк-кулны өчпочмаклы яулыкка асып куеп, буынны 8ле кебек бәйләвеч, шин ярдәмендә хәрәкәтсезләндерергә. Күгәргән урын тизрәк төзәлсен өчен, тирегә 0,25–0,5 процентлы йод эремәсе белән «челтәр» ясарга мөмкин. Моның өчен 5 процентлы йод эремәсен спирт яки аракы белән сыеклатырга кирәк. Баш, күкрәк һәм корсак бәрелгәндә, яшерен җәрәхәтләр барлыкка килергә мөмкин. Бу очракта кичекмәстән табибка күренергә кирәк. Бәрелгән урын күгәреп чыкканда, үзгәрешләрне күзәтеп тору хәерле. Әгәр ул урын тора-бара төсен кызылдан – аксыл шәмәхәгә, чия кызыл һәм зәңгәрдән саргылт яшелгә үзгәртә икән, димәк, барысы да тәртиптә. Әгәр ул тагын да ныграк кызарып, шешенү һәм сызлау көчәйсә, бәрелгән урынның үлекле башлавы ихтимал. Кичекмәстән табибка мөрәҗәгать итегез.

Пешү

Пешкән урынга иң элек салкын әйбер куярга кирәк. Аны краннан аккан салкын су астында тотсаң да була. Суык җылылыкның көчен киметә, пешкән урынга җәелергә ирек бирми. Пешкән урынга махсус мазь сөртү дә файдага гына булачак. Каш ясыйм дип күз чыкмасын өчен, пешкән урынга халык медицинасында тәкъдим ителгән төнәтмәләрне сөртергә, төрле үлән яфраклары куеп торырга ярамый. Юкса пешкән ярага инфекция эләгүе бар. Яралы урынга майлар сөртү дә тыела. Җәрәхәт җитди булганда, тиз арада табибка мөрәҗәгать итегез.

Кул, бармак киселү

Киселгән урын артык тирән булмаса, иң элек аны салкынча су белән юып алырга кирәк. Алга таба яраның кырыйларын (яраның үзен түгел!) хлоргексидин, водород перекисе, йод яки яшел су (зеленка) белән эшкәртегез. Аннары яра өстенә пластырь ябыштыру яхшы.

Суга бату

Суга батканда, кеше, куркудан, кул астында булган теләсә кайсы әйбергә тотынырга тырыша. Андый чакта кул астына коткаручы эләксә, икегезнең дә гомерenә куркыныч яный дигән сүз. Шуңа күрә суга батучы янына арттан йөзеп килеп, аны чәченнән яки култык астыннан эләктереп алырга кирәк. Алга таба аның йөзен өскә каратып, яр кырыена алып чыгу зарур. Суга батучының сулышы сизелмәсә, тиз арада аркасына яткырып, йөрәгенә массаж ясагыз. Үз аңында булган очракта, юеш киемнәрен салдырып, коры киемнәр киертергә, җылы чәй эчерергә кирәк.

Кояш сугу

Хәле начарланган кешене иң элек тизрәк күләгәгә яки салкынчарак урынга алып чыгыгыз. Башын югарырак күтәртеп яткырыгыз. Кысып торган киемнәрен салдырырга яки чишеп җибәрергә кирәк. Авыруның өстенә салкын су сибегез, юеш җәймә белән төреп куегыз. Маңгай турысына салкын суда чылатылган чүпрәк куегыз. Аңында булса, авыруга күп итеп су эчертегез. Күңеле болгана башласа, аны яны белән яткырыгыз. Бармакка бинт урап, авыз куышлыгын чистартыгыз. Косык массалары үпкәгә эләгергә тиеш түгел. Кеше аңын югалткан очракта, нашатырь спиртына манылган мамык иснәтеп, аңына китерергә кирәк.

Кешенең сулышы тоемланмаса, йөрәк тибеше сизелмәсә, йөрәккә массаж ясарга һәм ясалма сулыш алдырырга кирәк. Авыруга үзегез генә ярдәм итә алуыгызга шикләнсәгез, кичекмәстән табиб чакырыгыз. Кечкенә балага эссе сукса; зыян күрүченең тән температурасы 39 градуска кадәр күтәрелсә; кеше берничә минут дәвамында аңсыз ятса, авыр сулаunion; борынныннан кан китеп, 5 минут эчендә туктамаса, иң беренче чиратта табиб чакырырга кирәк.

Бал корты чагу

Корт чакканда иң беренче эш итеп энәсен чыгарып, яра урынын эшкәртергә кирәк. Корт агуына аллергиясе булган кешене иң элек чалкан яткырып, бүлмәне җилләтергә, буылса, ясалма сулыш алдырырга кирәк. Кортның энәсен пинцет ярдәмендә алырга, шул урынга боз куеп торырга яки спирт катнашмасы белән эшкәртергә, антигистамин дару эчәргә, преднизолон мазен сыларга кирәк.

Сорау – җавап

Күкрәк сөтеннән кайчан аерырга?

? Балага бер яшь тулгач, күкрәк сөте акрынлап файдалы үзлекләрен югалта башлый, суга әйләнә, шуңа күрә яше тулган баланы алга таба да имезүдән мәгънә юк, диләр. Яз көне баланы күкрәк сөтеннән аеру җиңелрәк, дигәнне дә ишеткәнем бар. Бу чынлап та шулаймы икән?

Чулпан ӘХМӘТШИНА. Сарман

Балага күкрәк сөте имезү буенча консультант Маргарита Марьина җавап бирә:
– Юк, бу фикер белән килешмим. Күкрәк сөте файдалы үзлекләрен беркайчан югалтмый. Киресенчә, сабыйны озаграк имезгән саен файдалырак, туклыклырак була бара ул. Мисал өчен, балага бер яшь тулганчы күкрәк сөтенең майлылык дәрәҗәсе 4,5 процент тәшкил итә. Өч яше тулганда инде ул 17 процентка (!) җитә. Әгәр бала күкрәк сөте белән хушлашуга яшь ягыннан да, психологик яктан да әзер икән, имезүне елның теләсә кайсы фасылында туктатырга мөмкин. Әмма моны кисәк кенә эшләргә ярамый. Баланы күкрәк сөтеннән аеру җайлап кына, акрынлап башкарылырга тиеш.

Белеп тор!

ТӨСЕНӘ КАРА

Баксаң, алманың файдасы аның төсенә карап аерыла икән.

✓ Яшел алма иң диетик һәм аллергиядән интегүчеләр өчен иң файдалы санала. Алар шулай ук зарарлы бактерияләр үсешен баса һәм ашкайнатуны яхшырта.

✓ Кызыл алма күзәнәкләрне вакытыннан алда картаюдан саклый ала. Кызыл алмаларның тышы С витаминына бай. Ул йөрәк-кан тамырлары авырулары вакытында ярдәм итә.

✓ Сары алма бавыр һәм үт куыгы эшчәнлеген яхшырта.

Бу – кызык!

Тамакка да, аякка да шифа

▶ Эремчектә аксым, май, кальций тозлары, фосфор күп. Майсыз эремчектә 17 процент аксым бар. Бу – итнең кайбер төрләрендәгегә караганда да күбрәк дигән сүз.

▶ Эремчек бавырда май тупланауын, тукымалар тыгызлануын булдырмый. Әмма әлеге сөт ризыгында бавыр юлларына утыручы терлек мае күп. Шуңа да эремчекне даими ашаганда аңа үсемлек мае өстәргә киңәш ителә һәм эремчекнең майсыз төрләренә өстенлек бирү яхшырак.

▶ Эремчек үзләштерелсен өчен, ашкайнату юлларының барлык әгъзалары да күп көч куярга тиеш була. Шуңа да аны көнгә 200 граммнан артык ашарга киңәш ителми.

Тамак авыртса. 200 грамм эремчеккә 2 баш суган турагыз. Әгәр эремчек салкын икән, аны җылытыгыз һәм артык суын сыгып алгач, муенга куегыз. Мондый дәвалау бәйләвечен берничә сәгать тотарга да, төнгелеккә калдырырга да мөмкин.

Аяклар даими шешенсә. Авырткан урынга эремчекле бәйләвеч кую ярдәм итә. Эремчек корырак булса яхшы. Бер сантиметр калынлыкта эремчек сыланган бәйләвечне көндез 3–4 сәгатькә куегыз. Шулай 2 атна дәваланырга кирәк. Көнаралаш аны вак угычтан уылган бәрәңге белән алмаштырырга мөмкин.

Ашказаны әчелеге югары булганда. 100 грамм эремчеккә 1 стакан ачы катык, 1/4 стакан сөт салып болгатыгыз да 2–3 сәгать караңгы урында тотыгыз. Ашаганнан соң 40 минут үткәч, аны 3әр аш кашыгы ашагыз.

Валентина СЕМЕНОВА

СИРЕНЬ ЧӘЧӘК АТКАНДА

Язның иртә һәм җылы килүе бакчачыларны алданрак кузгатты. Суган, кишер ише яшелчә генә түгел, хәтта помидор үсентеләрен ачык һавага утыртучылар да бар инде. Ләкин май – тотрыксыз ай: җылы һаваны салкыны алыштыру гына түгел, кыраулар да төшәргә мөмкин әле. Шулай да яшелчәне ачык туфракка кайчан утырту һәм чәчү дөресрәк? Ә суны ничек сибәргә? Булачак уңышны кыраулардан, корткычлардан ничек сакларга?

Күпләрне кызыксындырган шундыйрак сорауларга җавапларны «Россельхозцентр» оешмасының Татарстандагы филиалы җитәкчесе урынбасары Гүзәл ХӨСӘЕНОВАдан белештек.

– Язның соңгы аенда чәчәсен чәчеп, утыртасын утыртып бетерү мөһим. Кәбестәнең соң өлгерешле сортларын да ачык туфракка утыртуны июньгә калдырмау әйбәт. Помидор, кыяр, татлы борычка килсәк, аларын май урталарында утыртып, пленка белән каплыйбыз. Ә инде бу эшләрне халык сынамышларына таянып башкарсак, бөтенләй дә оттырмаячакбыз.

✓ *Кыярны ачык туфракка пленка астына кызыл миләш чәчәк аткач утыртырга мөмкин. Шуннан соң туфракта көчле кыраулар булмаячак инде.*

✓ *Чалмабаш (пион) бөреләнгәч, ташкабак һәм кабак утыртырга.*

✓ *Нәркисләр чәчәк аткач, кәбестә утыртырга, иртә өлгерә торган торма, борчак чәчәргә.*

✓ *Кәстәнә (каштан) чәчәк аткач, редисның җәйге сортларын, торма, ногыт борчагы чәчәргә.*

✓ *Сирень чәчәк аткач, иртә өлгерешле кыярны пленка астына утыртырга, яшел салат чәчәргә була.*

Шуны истә тотыгыз: май аенда үсентеләр әле бик нәзберек булганлыктан, аларга вакытында су сибеп торырга (2–3 көнгә бер тапкыр), тукландырырга кирәк. Бигрәк тә теплицадагы үсентеләрне онытмаска.

Газон үстерсәгез, май аенда аны инде кыркый башларга вакыт. Җир юеш булганда, таптамаска тырышыгыз. Юкса «пеләш»ләнә башлаячак. Кыркыганда, чүп үләннәрне йолкып ташларга иренмәгез.

vk.com

Кырау һәм корткыч

Җимеш агачлары чәчәк аткан чорда төнге кыраулардан сак булыгыз. Юкса суыктан өшегән чәчәкләре җимеш бирмәячәк. Моның өчен төтен шашкалары яки кечкенә генә мангал-мич (саклык белән генә төн буе яндырып чыгарга кирәк) кулланыла.

Агачлар чәчәккә бөреләнүгә, корткычларга каршы көрәшә башлыйбыз. Агач-куакларны үлән бете, талпан ише корткычлардан саклау өчен, 20 литр суга 60 грамм карбофос, 80 грамм бакыр хлорокисе һәм 40 грамм хлорофос салып болгатабыз. Эремәне агач ябалдашларына, куакларга бөркибез. Бөҗәкләр болай да бетмәсә, чәчәк атар алдыннан, бу эшне тагын кабатларга кирәк.

Бакчадагы барлык карлыган һәм крыжовник куакларын яхшылап карап чыгабыз. Чәчәк атканда һәм җимеш яралганда, аларга кырмыскалар бик нык зыян салырга мөмкин. Бөҗәкләрдән котылу өчен, тукыма кисәген керосинда чылатып, куак төбенә куеп калдырырга кирәк. Керосинны туфракка сибәргә ярамый, юкса үсемлеккә зыян килергә мөмкин.

Белеп тор!

Бакчачылар йодны фитофтора, ончыл чык (мучнистая роса), башка авыруларга каршы, шулай ук үсентеләрне тукландыру максатында куллана. Ләкин аннан саклык белән генә файдаланырга кирәк, юкса үсентеләргә зыян килергә мөмкин.

Йодны, гадәттә, тамчылап куллану киңәш ителә. Шуңа күрә аны буш корвалол шешәсенә бушатырга кирәк. Бу даруның дозаторы бар: аннан тамчылап кына тамызу бик уңайлы булачак.

Тукландыру

Сүз уңаеннан, бакчаның төп яме – гортензияләргә дә тукталып үтик. Май аенда чәчәкләрне тукландыру өчен, яшь кычыткannан файдаланырга мөмкин. Аны ваклап, савытка (яртылаш) тутырабыз. Шуннан, капкач белән каплап, җылы урынга куябыз. Бер атна дәвамында, әледән-әле болгатып, әчетәбез. Әзер эремәгә 1:10 нисбәтендә су өстәп, чәчәкләргә сибәбез.

Кыяр үсентеләренә килсәк, тутәлдә тернәкләнеп китүгә, авырулардан саклау өчен, болай эшләргә мөмкин. 8 литр суга 500 мл сөт, 0,5 чәй кашыгы йод һәм 15 г кер сабыны (барысын бергә яхшылап болгатабыз, сабын тулысынча эреп бетәргә тиеш) салып, эремә ясыйбыз. Үсентеләргә шуны аена ике тапкыр бөркибез. Болай эшләгәндә, кыяр, авыруларга бирешмичә, бик яхшы үсә.

Кыскасы, бакчабыз мул уңыш белән куандырсын өчен, үсемлекләрне бер генә көн дә куздән яздырмыйча үстерергә кирәк.

Аш-су

Яшел борщ

Румия ХӘЙРИЕВА рецепты

Витамин җитешмәгән язгы чорда бәһасез ризык бу! Яшь кычыткannан тыш, кузгалак, сәрдә үләне (сныть), тукранбаш яфраклары өстәргә мөмкин. Яшеллекне никадәр күбрәк салсагыз, борщ та шуның кадәр тәмлерәк килеп чыга.

Кирәк булачак: *2 л тавык шулпасы, уртача зурлыктагы 2 кызыл чөгендер, 1 кишер, 1 башлы суган, уртача зурлыктагы 2 бәрәңге, 1 аш кашыгы томат пастасы, 1әр бәйләм кычыткан, кузгалак, сәрдә үләне, кыздыру өчен – үсемлек мае, табынга куйганда өстәп җибәрү өчен – каймак.*

Бәрәңгене әрчеп, шакмаклап турыйбыз да кайнап торган шулпага салып, 10 минут пешерәбез. Шул арада башлы суганны, ваклап турап, үсемлек маенда кыздырып алабыз. Кишер, чөгендерне эре угыч аша чыгарабыз һәм, суган янына салып, барысын бергә кыздырабыз. Томат пастасы өстибез. Тоз, борыч сибеп, тагын 2–3 минут чамасы утта тотабыз. Кыздырылган яшелчәне шулпага салабыз.

Яшел үләннәрнең барысын да юып турыйбыз яки кул белән өзгәлибез һәм кәстрүлгә салып җибәрәбез. Бер минуттан соң газ утын сүндерәбез.

Һәр тәлинкәгә яшел тәмләткечләр һәм каймак өстәп, табынга куябыз.

Укучы хатлары

МОГҖИЗА-КАНӘФЕР

Бакчамда кәбестә бик уңа. Бер киңәшем белән укучыларны да таныштырмакчы булам.

Кәбестә кучанләнә башлагач, кайвакыт алданрак та, корткычлар яфракларын тишкәләргә тотына. Аларга каршы көрәшүнең мондый исулын сайлап алдым. Бер-ике кап канәферне төйгеч белән порошок хәленә китереп ваклыйм да һәр кучангә берәр чеметем сибеп чыгам. Әмма моны җилсез, коры көндә эшләргә кирәк.

Кәбестә яфраклары чип-чиста булып калачак, тишкәләнүдән туктаячак. Тик шунысы бар: канәфер порошогын личинкалар пәйда булганчы сибәргә кирәк.

Нина АЛЬМАНОВА. Мамадыш районы

КИМЕРҮЧЕЛӘРГӘ КАРШЫ – КӨЛ

Биш сутый җиребез һәм бакча йортыбыз бар. Элек агач йортыбызның идән астына күсе, тычкан иялешүдән интегә идек. Менә инде ике ел алардан башка яшибез.

Кимерүчеләрдән ничек котылдыгыз соң, дисезме? Идән астына көл катламы җәйдек (5 кв. м мәйданга 1 чиләк исәбеннән). Берничә көн узгач, чакырылмаган кунакларның эзе суынды. Баксаң, көл аякларына ябышып, тән тиресен әчеттерә икән. Тычкан көлне ялый һәм ул, авыз куышлыгына эләгеп, әчеттерә. Шулай итеп, кимерүчеләр бик тиз качып бетә.

Нурсәнә ИБРАҺИМОВА. Казан

Кирәге чыгар

Хуш исле җәймә

Урын-җирдән хуш исләр килеп торса, кәеф тә күтәрелеп китә. Моның өчен бөркегечле савытка 100 мл чиста су, 10 мл спирт, 20 тамчы ала миләүшәнең (лаванда) эфир маен өстәп, капкачын ябарга да кул белән селкеп болгатырга. Үтүкләр алдыннан җәймә, мендәр тышы ише урын-җир кирәк-ярагына шуны бөркергә. Хуш исләре бик озак сакланачак!

Белсәң, зыян итмәс

ДЖИНСЫ САЙЛАУ СЕРЛӘРЕ

Яз көне кием, өс-баш яңарту теләге көчәя. Шуны истә тотып, үзенә килешле джинсы чалбар сайлау серләренә тукталып үтик. Чыннан да, алар дәреслеккә бик нык туры килә! Ышанмасагыз, үзегез тикшереп карый аласыз.

1 Кыеграк урнаштырылган кесәлесе, турысына караганда, арт санны зуррак күрсәтә.

2 Арткы кесәләре арасына игътибар итегез: никадәр зуррак булса, ботлар шуның кадәр киңрәк күренә.

3 Кесәләренең зурлыгын үлчәмегезгә карап сайлагыз: кечкенә кешене зур кесә бизәми. Зур гәүдәле кешегә исә, киресенчә, кечкенә кесә килешми.

4 Чалбарның арткы ягындагы өстәп тегелгән кисәк «кокетка» дип атала. Аның җөе туры яисә V хәрефе рәвешендәрәк була. Кокеткасыз джинсылар да бар. Турысын түгел, ә нәкъ менә V рәвешлесен сайлап алу отышлы. Арт санны, ботларны ничектер җыебрак, матуррак күрсәтәчәк ул.

ҖАННЫ ТЫНЫЧЛАНДЫРУЧЫ ГЫЙБАДӘТ

Коръән укуның да үз әдәпләре бар. Аларны һәр мөселман белергә тиеш. Изге китапны бүләк итәргә ярыймы? Коръән укыган өчен мөселманга нинди савап языла? Коръән уку өчен билгеле бер вакыт бармы? «Өметлеләр» мәчете имам-хатыйбы Алмаз хәзрәт САФИНга шушы һәм башка сорауларны бирдек.

islam.ru

:: Алмаз хәзрәт, Коръәннең мөселман өстендә нинди хаклары бар?

– Коръәннең мөселман өстендә өч хакы бар: андагы һәрбер аятькә иман китерү, Коръәнне гарәпчә укырга өйрәнү, мәгънәләренә төшенү, андагы хөкемнәр белән гамәл кылу.

:: Коръән укуның нинди саваплары бар?

– Коръән уку – күңелне тынычландыручы һәм җанны дәвалаучы гыйбадәтләрнең берсе ул. Аллаһы Тәгалә: «Без мөэминнәргә Коръәннән шифа һәм Аллаһның рәхмәтен индерәбез», – диде. Коръәнне еш укучы, ятлаучы, аны башкаларга өйрәтүче кеше Аллаһның иң сөекле бәндәсе була. Мөхәммәд пәйгамбәр әйтте: «Дөреслектә, Аллаһы Тәгаләнең кешеләр арасында иң хәерлеләре бар». Кешеләр: «Кемнәр соң алар, йә Аллаһның илчесе?» – дип сорады. Мөхәммәд (с.г.в.): «Алар – Коръәнне укучылар. Алар – Аллаһның кешеләре һәм Аның сайлап алган бәндәләре», – дип әйтте.

Һәрдаим Коръән укылган җиргә бәрәкәт һәм тынычлык иңә. Фәрештәләр мәчеткә җыелып Коръән укучы һәм аны өйрәнүче кешеләр өчен хәер-бәрәкәт сорап дога кыла. Коръәнне оста итеп укучы кеше Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәтле фәрештәләр дәрәҗәсенә күтәрелә, ә авырлык белән тырышып укучы кешегә ике тапкыр артык әҗер-савап языла. Шулай ук кешенең җәннәттәге дәрәҗәсе дә Коръәнне күп укуына һәм ятлавына бәйле.

:: Изге китапның тәрҗемәсен, тәфсирен укыган өчен дә савап языламы соң?

– Коръән китабын Аллаһы Тәгалә индергән рәвештә гарәп телендә уку әҗер-савап китерүче һәм Аллаһка якынайтучы гыйбадәт булып санала. Хаббәб ибен әл-Әрат исемле олуг сәхабә бер кешегә болай диде: «Булдыра алганча Аллаһка якынай һәм бел ки, син Аңа аның өчен Коръән сүзләренә караганда да сөеклерәк булган башка нәрсә белән якыная алмаячаксың».

Коръәнне яттан укуга караганда китаптан уку яхшырак. Чөнки күзләр белән аятьләргә карау шулай ук әҗер-савап китерүче гыйбадәт булып санала. Әгәр дә бер кеше Коръәнне гарәпчә укыса, аңа укыган һәр хәреф өчен ун әҗер-савап була.

Шулай ук Коръәннең тәрҗемәсен яки тәфсирен уку да саваплы гамәл булып тора. Әгәр дә мөселман гыйлем алу нияте белән Коръәннең тәрҗемәсен яки тәфсирен укыса, аңа шуның өчен әҗер-савап языла. Мөхәммәд (с.г.в.): «Сезнең иң хәерлегез –Коръәнне өйрәнеп, аны башкаларга өйрәтүче кеше», – диде.

:: Коръәнне бүләк итәргә ярыймы? Китапны ничек сакларга?

– Коръәнне аңа иман китергән һәм аны укый торган мөселманга бүләк итәргә ярый. Коръәнгә хөрмәт күрсәтү Аллаһны зурлау булып тора. Шуңа күрә аны йортның иң хөрмәтле урынында, кендектән биегрәк булган урында сакларга кирәк. Кем дә кем Коръәнгә хөрмәт күрсәтсә, бу гамәл күңелдә тәкъвалык сыйфаты барлыгын күрсәтә. Аллаһы Тәгалә дә әйтте: «Кем дә кем Аллаһның динә билгеләгән нәрсәләрен зурласа, бу – күңелләрнең тәкъва булуыннан».

Коръән китабы иң изге китап булганга күрә аның өстенә башка китапларны яки берәр әйберне куярга ярамый, чөнки бу аңа карата хөрмәтсезлек күрсәтү була. Имам әл-Бәйһәкый үзенең «Шүгабүл-имән» исемле китабында Коръәнгә карата күрсәтелергә тиешле әдәпләр хакында болай диде: «Коръән китабына башка китап, кием һәм башка нәрсәләр куелмый. Бары тик бер Коръән китабы өстенә икенче Коръән китабын гына куярга ярый». Шулай ук әл-Хәким әт-Тирмизи исемле галим «Нәвәдиру әл-Усуль» исемле китабында: «Коръән китабын ачык килеш калдырырга һәм аның өстенә башка китапларны куярга ярамый. Коръән һәрвакытта да башка китаплардан өстә торырга тиеш», – дип әйтте.

:: Бүләк ителгән Изге китапны бер дә укымыйча, тотмыйча, тик яткызу гөнаһмы?

– Мөселман кеше, һәр көнне яттан яки китаптан карап, Коръәнне укырга тиеш. Чөнки Коръәнне уку – Аллаһны ярату билгесе. Госман ибен Гаффән исемле икенче бер олуг сәхабә болай диде: «Әгәр дә сезнең күңелләрегез чиста булса, сез Раббыгызның сүзе булган Коръәнне укып туймас идегез».

Дин галимнәре аңлатуынча, Коръән сүрәләрен һәм аятьләрен намаз эчендә уку фарыз, ә намаздан тыш вакытта уку – сөннәт гамәл. Әгәр дә үзен мөселман дип санаган кеше Коръән китабын намаздан тыш укымаса, ул Мөхәммәд пәйгамбәрнең сөннәтен үтәмәгән була.

> Коръәннең бер үзенчәлеге – аның тиз онытылуы, хәтердән чыгуы. Кешеләр һәр көнне Коръәнне укысыннар һәм ятласыннар өчен, Аллаһы Тәгалә аны тиз онытыла торган итте дә. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Коръәнне гел укып-кабатлап торыгыз. Җаныма хуҗа булган Аллаһ белән ант итәмен ки, ул бауга бәйләнгән дөягә караганда да тизрәк кача, ягъни тиз онытыла», – диде.

Моннан дүрт еллап элек, Мостай Кәримнең «Безнең өйнең яме» повесте буенча төшерелгән «Сеңелкәш» фильмы чыккач, Башкортстан киносы бездән бер адым алда бара, дигән нәтиҗәгә килгәннәр иде. Эчтәлек һәм форма ягыннан шактый камил булган «Помилование» фильмын тәкъдим итеп, алар тагын бер адым алга атлады.

Кино нәрсә хакында соң? Иң әүвәл вакыйгаларның Бөек Ватан сугышы елларында барганын искәртеп үтик. 1942 елның җәе. Сталинград янындагы канкойгыч сугыш, кырыс командирлар, дуслык, тугрылык һәм... мәхәббәт. Режиссер сүзләре белән әйтсәк, «Помилование» – сугыш түгел, ә адәм баласының язмышы, кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләр турындагы фильм.

– Без эчтәлек ягыннан гаять көчле әсәргә нигезләнеп эшләдек. Мондый тарихны уйлап таба алмас идек. Шуңа күрә, төп ярдәмчебез Мостай Кәрим үзе булды, дип әйтергә тулы хакыбыз бар дип саныйм. Шуны искәртәсем килә: без сугыш турында фильм төшермәдек. Монда хәрби хәрәкәт түгел, кеше күңелләренең «хәрәкәте» беренче урында, – дип сөйләде безгә Айнур Әскәров.

Фильмның төп продюсерларының берсе – әдипнең оныгы Тимербулат Кәримов. Режиссер сүзләренә караганда, әлеге әсәргә алынырга нәкъ менә Мостай Кәримнең туганнары тәкъдим иткән.

– Мондый әсәр белән эшләү – үзе бәхет инде ул. Ә миңа икеләтә бәхет елмайды: оештыру эшләренә бөтенләй дә «кысылмаска» мөмкинлек бирделәр. Бары иҗат белән генә шөгыльләндем. Бик рәхәт икән, – ди ул.

«Помилование» фильмында төп рольләрнең берсен башкарган Александр Новиковка – 18 яшь. Герое Любомир белән холыклары бик охшаш икән. «Тормышымда фильмдагы кебек сайлау алдында калсам, нәкъ Любомир кебек эшләр идем», – диде ул премьера алдыннан. Башкортстанның Чишмә районында туган егет – Җантимер Байназаров ролен уйнаган Николай Галләмов берничә көн хәрби киемен салмыйча йоклавын әйтте. «Вакыйгалар сугыш чорында бара. Героемны яхшырак аңлар өчен эшләдем мин моны. Төшергән вакытта телефоннарны да кулланмадык. Ул чакта кеннәр ничек узган, кешеләр бер-берсе белән ничек аралашканнар – шул тормыш белән яшәп карадык», – диде ул. Испан коммунистларының кызы Мария-Тереза ролен башкарган Җәмилә Мөдәрисова өчен әлеге фильм – тәүгесе. Борчылуын яшермәде 16 яшьлек кыз. Ничек кенә булса да, әлеге яшь актерларның Мостай Кәримне, аның геройларын аңлап эшләгәннәре күренә иде.

Фильм Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның да күңеленә хуш килгән. «Карарга киңәш итәм – бик гыйбрәтле тарих», – дип бәяләгән ул аны «Телеграм»дагы каналында. Беренче тамашачылар арасында аннан тыш та шактый гына рәсми затлар күренде.

«Помилование» фильмын Россиянең 1700 кинотеатрында карап булачак. «Яратырга, бирелгән боерык беркайчан да кире кагылмый» шигаре белән тәкъдим ителгән әлеге кинокартина 12 яшьтән өлкәнрәкләр өчен каралган.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

БЕЛОРУССИЯДӘ КАЛГАН ЭЗЛӘР

Күптән түгел Бөтендөнья татар конгрессының төбәкчеләр төркеме, галимнәр, җәмәгать эшлеклеләре, журналистлар, Белоруссиядә яшәүче татарлар белән күрешеп, аралашып кайтты. Алар бу илдә ниләр күргәннәр, нинди тәэсирләр белән кайтканнар? Конгрессның Төбәкләр белән эшләү комитеты җитәкчесе Альберт БОРҺАНОВтан шул хакта сораштык.

:: Альберт Әхмәтҗанович, бер атна буена сузылган сәфәрдә күңелгә иң уелып калганы ни булды?

– Мөгаен, Бөек Ватан сугышына кагылышлы вакыйгалардыр. Бу минем үземә дә бәйле. Әтием Әхмәтҗан Борһанов нәкъ менә Витебскины азат итү өчен сугышларда башта «Батырлык өчен» медаленә, аннан Полоцк шәһәрен азат иткән өчен Кызыл Йолдыз орденына лаек була. Сәфәребезнең төп максаты Бөек Ватан сугышы тарихын барлау, Белоруссия кырларында ятып калган якташларыбызны искә алу, аларның рухына дога кылу һәм Минскида «Беларусь Республикасы татарлары: тарих һәм хәзерге заман» темасына халыкара фәнни-гамәли конференция уздыру иде.

:: Ниләр күрдегез?

– Безне башта Витебск өлкәсендә урнашкан «Рыленки» каберлегенә алып бардылар. Анда бу төбәкне фашистлардан азат иткәндә һәлак булган 9,5 мең Совет солдаты җирләнгән. Татар фамилияләре дә күп. Араларында танылган татар композиторы, «Шүрәле» балеты авторы Фәрит Яруллин да бар. Ул 1943 елның октябрендә Дубровенск районында һәлак була. Район үзәге булган Дубровно шәһәрендә Фәрит Яруллин исемен йөрткән сәнгать мәктәбе дә бар. Ул 2017 елда ачылган. Мәктәп бакчасында композиторга һәйкәл дә куелган. Районның төбәк тарихын өйрәнү музеенда Фәрит Яруллинга багышланган аерым витрина да бар. Анда композиторның берничә фотографиясе, биографиясе, ноталар, «Шүрәле» балеты афишалары, һәйкәл ачу тантанасыннан фотолар куелган.

Таныш исемнәр тагын да очрады әле. «Казанские ведомости» газетасы мөхәррире Венера Якупованың бабасының энесе Әнвәр Якупов каберенә юлыктык. Үзебезнең арада да алдан белешеп, әзерләнеп килүчеләр булган икән. Питрәч районының Чыты авылы мәдәният йорты мөдире, блогер Миңнур Шәмсетдинов авыл зиратыннан алынган берничә уч туфракны «Рыленки» каберлегенә салды. Ул тарих белән дә кызыксына. Алты авылдашы Белоруссиядә ятып калган. «Авылда әбиләр, сугышта ятып калган ирләрен сагынып, каберләренә бер уч туган җир туфрагы салу турында хыяллана иде. Шул искә төште», – ди. Берсенең фамилиясен, 1895 елгы Абдулла Камалов дигәнен шул мемориалдан тапты да ул. Әйтергә кирәк, эзтабарлар якын-тирәдәге урманнардан, сазлыклардан сугышчыларның калдыкларын һаман да таба тора әле. Мемориаль такталарга ел саен яңа исемнәр өстәлә бара.

Белоруссиядә Бөек Ватан сугышына караган каберлекләр бик күп. Дубровно шәһәреннән соң Копти авылында булдык. Биредә Белоруссияне фашистлардан азат иткәндә һәлак булган татарларга аерым мемориаль такта куелган. Анда 10 меңнән артык татар һәлак булганлыгы язылган. Белоруссиядә ятып калган татар сугышчылары – Советлар Союзы Геройлары исемлеге дә уеп куелган. 14 Герой арасында Газинур Гафиятуллин, Ольга Санфирова исемнәре бар. «Мәдәни җомга» газетасының баш мөхәррире Вахит Имамов әлеге исемлектә Актаныш районы Татар Әҗбие авылында туып үскән Советлар Союзы Герое Баян Дәүләтов исемен тапты. Ул 19 яшендә һәлак була. Копти авылындагы мемориаль комплекс армия генералы, заманында Хәрби фәннәр академиясе президенты булган Мәхмүт Гәрәев инициативасы белән эшләнә. Ул үзе дә шушы җирләрне азат итүдә катнаша.

:: Җирле халыкның безнең сугышчылар каберлекләренә мөнәсәбәте ничек?

– Мондагы мөнәсәбәтләргә гаҗәпләнерлек тә, сокланырлык та. Барысына да зур хөрмәт белән карыйлар. Минск районы хәрби комиссары Дмитрий Годун каберлекләрне саклауга мәктәп укучылары да җәлеп ителгәнен әйтте. Минск районындагы Волковичи авылы янында Кызыл Йолдыз ордены кавалеры, Кызыл Армия капитаны Әдһәм Кәримов җирләнгән урында да мемориаль комплекс төзелгән. Безнең төркем аны ачу тантанасында да катнашты. Каберенә чәчәкләр салдык. Нәселе буенча чыгышы Казаннан булган, Казахстанда туып-үскән татар каһарманы 1944 елның 7 июлендә 28 яшендә һәлак була. Мемориаль комплекс Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов ярдәме белән төзелгән. Ә исемен мәңгеләштерүне Казахстанның татар һәм башкорт ассамблеясы җитәкчесе, мәрхүмнең туганнан туганы Тәүфыйк Кәримов оештырган. Авылның зиратка бара торган урамына да Әдһәм Кәримов исеме бирелгән.

Витебск шәһәрендә Советлар Союзы Герое Минай Шмырев музее белән таныштык. Биредә партизаннар эшчәнлегенә бәйле истәлекләр саклана. Безнең өчен иң мөһиме 825 нче Идел татар легионының 1943 елда Көнбатыш Двина елгасы буенда партизаннар ягына чыгу тарихы булды. Хәтерләсәгез, бу вакыйга Муса Җәлилнең «Двинага» шигырендә дә тасвирлана. Музей хезмәткәрләре бу тарихны җентекләп өйрәнгән, моңа бәйле бик күп документлар тупланган. Бер уйласаң, гаҗәп инде: тарихыбыз белән читләр кызыксына, безнең әлләни ис китми кебек.

Татар эзе Брест ныгытмасында да сакланган. Биредә Питрәч районының Әлбәдән авылында туып-үскән Петр Гавриловның 1945 елда тутырылган шәхси карточкасының күчермәсе саклана. Әлеге документта аның милләте татар дип күрсәтелгән.

:: Татарлар тарихы белән беренче чиратта, мөгаен, Белоруссиядә яшәүче милләттәшләребез кызыксына торгандыр?

– Анысы да бар. Без бит инде юкка гына, милләттәшләребезне барлап, халыкара фәнни-гамәли конференция үткәреп кайтмадык. Анда конгрессның Милли Шурасы рәисе Васил Шәйхразыев та, гомумән, 100гә якын кеше катнашты, 50 галим һәм төбәкче чыгыш ясады. Милләттәшләребез Мари Иле республикасы, Пермь крае, Омск, Оренбург, Пенза, Ярославль, Түбән Новгород өлкәләреннән дә килгән иде. Белоруссиядә яшәүче милләттәшләребез андагы татарларның тарихын һәм хәзерге тормышын чагылдырган күргәзмә дә оештырган иде. «Чишмә» татар-башкорт мәдәни мирасы» халыкара иҗтимагый берләшмәсен Эльвира Левшевич җитәкли. Ул Башкортстанның Кушнаренко районындагы Шәрип авылында туып-үскән. Кияүгә чыккач, Белоруссиягә күченгән. Татар телендә бик иркен аралаша. Эльвира даими төстә чараларга 130лап татарның йөрүен әйтте. «Милләттәшләребезне берләштереп кенә калмыйбыз, Белоруссия халкына милли моңнарыбызны, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне танытабыз», – диде. Ул Белоруссия татарларының «Ләйсән» фольклор ансамблен дә җитәкли. Анда бер казах кызыннан кала барысы да татарлар. Киемнәре дә искитәрлек, махсус дәүләт программасы кысасында тегелгән. Кызларның аякларындагы читекләр Арчаныкы булып чыкты. Татарстан бүләге икән. Татар телен югалтмас өчен, әдәби китаплар укыйлар. Үзара да, гаиләләрендә дә туган телдә аралашырга тырышалар. Якшәмбе мәктәпләрендә дә татар телен өйрәнергә була.

Альберт Борһанов архивыннан

Советлар Союзы Герое Петр Гаврилов һәйкәле янында.

:: Бөек Ватан сугышына кагылышлы вакыйгалар күңелгә уелып калды дип әйтүегез, чыннан да, хак булып чыкты. Бу хисләр сезне Белоруссия чиген үтеп чыккач та ташламаган. Смоленск өлкәсенең Вязьма шәһәрендә һәлак булган солдатларга, Советлар Союзы Герое Ефремовка куелган һәйкәл нәрсәсе белән җәлеп итте?

– Анда кагылмыйча берничек тә үтеп китә алмадык. Беренчедән, бу һәйкәл Бөек Ватан сугышы истәлегенә салынган беренче монумент булып исәпләнә, икенчедән, анда шулай ук бик күп милләттәшләребез ятып калган. Аларны да догадан калдырмадык. Тарихтан билгеле булганча, 1941 елның октябрендә Вязьмада иң зур бәрелешләрнең берсе башлана. Гитлер, Мәскәүгә барып керү максаты белән, бу юнәлешкә иң куәтле армиясен җибәрә. Советлар Союзына Мәскәү янында көч туплау өчен, фашистларны Ржев белән Вязьма арасында тоткарлап торырга кирәк була. Кызыл Армия, зур югалтулар хисабына булса да, максатына ирешә. 1942 ел башында Вязьманы азат итү өчен генерал Ефремов җитәкчелегендәге армия җибәрелә, әмма ул чолганышта кала. Шулай булса да, ике ай ярым чамасы дошманнарга каршылык күрсәтә. Сталин генералны коткарырга самолет җибәрә, әмма ул китми. Каты яралана. Әсирлеккә төшмәс өчен, соңгы патронын үзенә ата.

Кан белән сугарылган сугыш эзләре җуелмый. Әмма бу эзләрне мыскыл итүчеләр дә, белоруслар кебек кадерләп саклаучылар да бар. Без бу сәфәрдән Белоруссия халкына бик рәхмәтле булып кайттык.

Әңгәмәдәш –
Фәния ӘХМӘТҖАНОВА

vk.com

АРЗАН ҖЫЕРЧЫК

Кесә такыр булса да, матур буласы килә! Россиядә яшәүче гүзәл затларның күбесе шул фикердә. Махсус салоннарга йөрү кесәгә шактый сукканга күрә, соңгы арада аларның күбесе үзенә үзе (!) матурлык уколлары ясый башлаган әнә. Өйдән чыгып торасы да юк, акча да янга кала. Белгечләр исә, болай эшләү коточкыч дәрәҗәдә куркыныч, дип чаң суга. Арзан уколлар белән җыерчыктан котылырга маташу күпмегә төшә?

Мондый могҗизалы уколларны барыбызга яхшы таныш «Озон», «Вайлдберриз» кебек маркетплейслардан алып була. Күбебез гадәти кибетләргә йөрүдән бизеп, киемен дә, ризыгын да, көнкүреш кирәк-ярагын да шуннан гына ала бит хәзер. Соңгы арада маркетплейслар матурлык салоннарын да алмаштыра башлаган.

Бүген биредә, нигездә, өч төрле матурлык уколы сатыла. Аларның берише ирен күпертү өчен кирәк булса, икенчеләре биттәге җыерчыкларны киметеп (филлер), артык майны «яндыру» өчен (липолитик) кирәк. Бәяләре шактый очсыз. Матурлык салоннарында берничә дистә мең сумга сатып ала торган әлеге уколларны биредә, күп дигәндә, 12 мең сумга алып була. 3 мең сумлыклары да бар. Бар да бер капта ничә ампула булуга бәйле. Кабында ничек итеп кулланасы да язылган! Аңлашылмаса, «Ютуб»та мондый уколларны ничек ясыйсын өйрәткән видеолар да бар.

Маркетплейста сатылган һәр препарат астында йөзәрләгән кайтаваз. Ни гаҗәп, аларның барысы диярлек уңай! Шунда ук матурлык уколларының нәтиҗәсен күрсәткән фотолар да урнаштырганнар.

Фотосы буенча 25–30 яшьләр тирәсендәге Ирина исемле кыз мондый укол ярдәмендә кабартылган иреннәнән бик канәгать булуын язган әнә. «Биш ел чамасы косметологка йөргән идем. Күпме акча түктем. Хәзер ул клиникаларга бөтенләй якын килерлек түгел. Әллә кайчан шушы уколны алып ясыйсы калган. Бер авырлыгы да юк», – дип язып калдырган ул. Туташларның икенчесе үзенә үзе укол ясарга курыккан. Әмма аптырап калмаган, ирен күпертүче уколны дус кызыннан ясаттырган. Шулай ук нәтиҗәсеннән канәгать калган. Шул рәвешле бу препарат астында калдырылган 130 кайтавазның нибары берсе генә тискәре. Алсу исемле бер хатын-кыз бу уколны кадаганнан соң иреннәренең кара янып чыгуын язган. Фотосын да урнаштырган. Әмма башка кызларның кайтавазлары арасыннан аны бик тырышып эзләсәң генә таба аласың! Шуңа бу уколның файдадан гайре бернәрсәсе юк икән дигән фикер кала.

Психология фәннәре магистры, психолог Чулпан Нигъмәтҗанова-Гарәфиева сүзләренә караганда, мондый «матураю» ысуллары, нигездә, үзендә гел нәрсәдер үзгәртеп торырга теләүчеләр куллана. Жир йөзендә яшәүчеләрнең якынча 3 проценты психикасында шундый тайпылыш бар икән. Психологиядә бу күренеш дисморфофобия дип атала.

– Чынлыкта бу кешеләргә тәненнән бигрәк психикасын җайга салу турында уйланырга кирәк. Алар үзен ничек бар шулай кабул итми, башкалар ни уйлар дип куркып яши, – ди психолог. – Матурлык уколларын шундый җиңел юл белән сатып алу мөмкинлеге, аларны куллаучылар саны арту җәмгыятебездә үз-үзеннән канәгать булмаучыларның ни дәрәҗәдә күп булуын күрсәтә. Ләкин кеше психологик ярасыннан арынасы, психикасын төзәтәсе урынга, укол ярдәмендә вакытлыча булса да күз буярга тырыша. Әгәр дә кеше эшне шуннан башласа, арабызда ирен күперту, керфек үстерү, җыерчыкларны бетерү артыннан чабучылар да азрак булыр иде. Матурлык уколлары ярдәмендә генә үз-үзеңне кабул итү, ярата башлау – иллюзия.

Таныклык кирәк

Юрист Роман Архипов сүзләренә караганда, закон нигезендә барлык матурлык уколларының да теркәү таныклыгы булырга тиеш. Әгәр ул шушы документтан башка сатыла икән, димәк, аларны йә идән астыннан таратып аталар, йә ул «тәнгә кертелми торган чара» буларак сатыла.

– Закон нигезендә барлык медицина чаралары, шул исәптән имплант (филлер, мезонин һ.б.), дару рәвешендәге инъекция препаратлары (ботокс, мезотерапия һ.б.) да махсус теркәү таныклыгы белән генә сатылырга тиеш. Ул аларның нәтиҗәле һәм куркынычсыз булуын раслый. Мондый документлы матурлык уколларын дипломлы белгеч яки медицина лицензиясе булган юридик зат кына сатып ала ала. Гади кешегә аны кулга төшерү бик авыр, – ди юрист.

Шуңа күрә мондый чын матурлык уколларының «Озон», «Вайлдберриз» кебек кибетләрдә сатылмавы көн кебек ачык. Аларны маркетплейслардан алып куллану аркасында зыян күргән очракта да беркемне дә җаваплылыкка тарта алмыйсың.

Ансар хәзрәт МИФТЯХОВ,
«Мәрҗани» мәчете имам-хатыйбы:
– Тәнебез безгә җаныбыз кебек үк әманәт буларак бирелгән. Тәннең хуҗасы – Аллаһы Тәгалә. Ул безгә чиста тән биргән икән, без аңа аны шундый ук чиста хәлдә кире кайтарып бирергә дә тиешбез. Әгәр дә без аны төрле үзгәрешләр белән кайтарабыз икән, безгә Аллаһы Тәгаләнең ачуы, ләгънәте булачак. Әгәр кеше, берәр бәла-казага дучар булып, тәненә зәгыйфьлек килсә һәм ул аңа алга таба яшәргә комачауласа, ул вакытта тәнне, әгъзаларны төзәтергә, үзгәрешләр кертергә рөхсәт ителә. Әгәр бу эш Аллаһы Тәгалә биргән матурлыктан риза булмыйча, кемнедер кызыктыру, башкалардан аерылып тору, калышмау өчен эшләнә икән, ул гөнаһ санала.

«СУКЫРАЕРГА МӨМКИН»

Арзанлы матурлык уколлары организмга ничек тәэсир итә? Әлеге һәм башка сораулар белән КФУның Университет клиникасы табиб-дерматовенерологы, косметолог Эльвира МАГЕРРАМОВАга мөрәҗәгать иттек.

:: Сезгә килүчеләр арасында арзанлы матурлык уколларыннан зыян күрүчеләр бармы?

– Соңгы арада арзанлы матурлык уколлары корбаннары саны, дөрестән дә, арта башлады. Безгә нигездә 20–25 яшьлек кызлар ярдәм сорап мөрәҗәгать итә. Күбесе иреннәрен күпертү өчен үзләренә үзләре белер-белмәс укол ясаган. Энә тигән урыннарда кара янган гематомалар пәйда булган, иреннең формасы бозылган. Арзанлы матурлык уколлары китергән мондый зыянның нәтиҗәсен бетерү өчен бик күп көч һәм вакыт таләп ителә.

:: Маркетплейслардан сатып алынган андый уколлар тагын нәрсәсе белән куркыныч?

– Алар аркасында кешенең мимикасы, тән тиресе бозыла, йөз һәм гәүдә бик нык шешенә, ямьсез эзләр кала. Җыерчыкларны тигезли торган филлер, артык майны «яндыра» торган липолитикларны профессиональ косметологлар рәсми дистрибьюторлардан гына сатып ала. Сыйфаты начар булып чыкса, арадашчы оешма вәкиле, җитештерүчегә чыгып, проблеманы тиз арада хәл итә. Шуңа күрә мондый матурлык уколларын рәсми булмаган арадашчылардан алу бик куркыныч. Син аның яраклылык вакыты чыкканмы-юкмы, составында зарарлы химик матдәләр бармы икәнлеген дә белмисең. Бәлки, ул шприцта аллергия, анафилактик шок, күзәнәкләрнең үлүенә (некроз) китерә торган зарарлы матдәләр бардыр? Теләсә каян сатып алган очракта моны беркем төгәл белми, аның өчен беркем җавап та бирми. Шуңа күрә мондый матурлык уколларын сыналган, билгеле оешмалардан фәкать тәҗрибәле косметологлар гына сатып алырга тиеш.

:: Аларны сайлау гына түгел, дөрес итеп ясый белергә дә кирәк бит әле...

– Әлбәттә! Белер-белмәс үзенә мондый уколлар ясаган кеше аны ничек дөрес башкарасын да, шприцтагы сыекчаны күпме кертәсен дә белми бит. Ул энәне дөрес яктан кертмәсә яки артык тирән кадаса, тәннең, әйтик, шул ук иреннең формасы бозылачак. Әгәр ул укол ясаганда кан тамырына эләксә, бөтен күзәнәкләргә зыян салачак. Хәтта тәҗрибәле белгеч тә бу эшләрне башкарганда бик сак эш итә. Ул-бу була калса, хатасын ничек төзәтәсен белә. Үз-үзенә мондый укол ясаучылар исә тәненә гомерлек зыян сала ала. Дөрес ясалмаган очракта, мондый матурлык уколлары кан тамырларын кысарга да мөмкин. Бу исә, үз чиратында, кан әйләнеше бозылуга, ишемиягә үк китерә ала. Филлер эре кан тамырларына эләксә, кеше сукыраерга да мөмкин. Майларны «яндыручы» липолитикларны дөрес салмаганда, тән тукымасы үлекле. Аннары мондый уколлар бик чиста урында, махсус шартларда гына ясалырга тиеш. Өйдә ясалган очракта, организмга инфекция эләгүе дә бар.

:: Үзлегеңнән укол кадагач, организмдагы нинди үзгәрешләр сагайтырга тиеш?

– Әгәр укол ясаган урын авыртса, агарып яки шешеп чыкса, оеса, кичекмәстән, табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк.

– Маркетплейслардагы ирен кабарта, җыерчык бетерә торган кирәк-яракларның ни дәрәҗәдә сыйфатлы, ялганмы-чынмы икәнен кеше үзлегеннән дә тикшереп карый ала. Моның өчен Росздравнадзор (**roszdravnadzor.gov.ru**) сайтындагы «Теркәлгән медицина эшләнмәләренең бердәм реестры» дигән бүлеккә кереп, әлеге препарат турында кирәкле барлык мәгълүматны кертеп, аның бу исемлектә бармы-юкмы икәнлеген белергә мөмкин, – ди юрист.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ГӨЛСӘРИЯ ШӘЙХРАЗИЕВА:

«КАЕНАНАМ КИЯҮГӘ ЧЫКМАСКА КУШТЫ»

Парлап йөрисе килгән чаклары була аның... Якыннары, дус-ишләре бәйрәмгә чакырганда, кайчак ялгыз булганга бармый да кала. Барса да, бик кыенсынып тора, кеше ирләре сүз катмаса ярар иде, дип кенә йөри. Барган җирендә озак тормаска тырыша... Эштә бераз соңарса да, каенанасы эзләп чыга үзен.

Тукай районының Боерган авылында яшәүче 66 яшьлек Гөлсәрия Шәйхразиева ире белән алты ел гына яшәп кала. 32 яшендә тол калган хатын тагын 19 ел каенанасы белән гомер кичерә.

– Бик акыллы гаиләгә килен булып килдем. Танышкан чакта ирем Вәзиф сөт машинасында эшли иде, мин бухгалтериядә утырам. Дуслашып киттек. Иремне бик ошаттым. Дөньяда андый кеше башка юктыр ул. Эчмәде, тартмады, авыр сүз әйтмәде. Әрәм булды шул бәгырькәем. Кем уйлаган бит! Ул чакта ике балабыз бар иде инде. Олысы Илнурга – 5, Фәнискә 3 кенә яшь иде әле. Алар туйганчы «әти» дия алмады, үзем ир назын күрмичә калдым, – дип сөйли Гөлсәрия апа. – Ул чакларны уйласам, әле дә йөрәгемнән кан тама кебек. Вәзиф үлгәннән соң 5–6 ел кеше рәтенә керә алмадым. Үз-үземне кая куярга да белмәдем. Кайлардан сабырлык алганмындыр инде. Үз әнием исән иде әле ул чакта. Ул гел бер сүзне кабатлады: «Кодагыйга сүз әйтмә, каты бәрелә күрмә». Дөнья мәшәкате белән мин үземне уйламадым да. Ике баламны кеше итим дип эшләдем дә эшләдем.

Нидер буласын йөрәге сизенә аның. Фаҗигагә 3–4 көн кала тынычсызлана Гөлсәрия апа, үз-үзенә урын таба алмый башлый. Озак та үтми, 1989 елның 17 мартында Вәзиф абый юл фаҗигасендә вафат була. Өй җиткерергә йөргән чаклары. Вәзиф абый, Удмуртиядәге осталар белән сөйләшеп, алар янына кузгала. Алабугага җитәрәк, юл сорарга дип, машинасын туктата да төшә. Әҗәле шунда көтеп тора да инде аны. Юл кырыеннан барган ирне йөк машинасы таптап китә. Әнә шуннан соң Гөлсәрия апа ир дә, хатын да булып яши башлый. Абзар тулы малларның берсен дә бетерми. Киресенчә, уллары бернигә

Гөлия Ибәтуллина фотосы

дә тилмермәсен өчен, тагын да арттыра. Сыерларның саны бүген дә унике икән. Үгезләре дә бар, бозаулары да дүртәү. Гөлсәрия апа әле дә туктарга уйламый.

> Авыл җирендә йоклап ятып булмый. Иртәнге якта башта өй эшен бетерәм. Сыерларны савам, асларын чистартам, сөтләрен тапшырам, аннан эшемә китә идем. Балаларны карарга инәй булды. Вәзиф аның бердәнбер баласы иде. Шуңамы инәй мине үз кызы кебек күрде. Ирем үлгәч, кияүгә сорап килүчеләр булса да, бирмәде.

– Мин үзем дә иң элек улларымны уйладым. Үги ата үзеңнеке булмас, дидем. Чит кеше синең балаңа бер кисәтү ясаса да кыен бит ул. Аларны кактырып суктырасым килмәде, – ди Гөлсәрия апа. – Хәер, үземнең дә башка кеше белән тормыш корасым килмәгәндер инде, дим хәзер. Әле кайберләренә шаяртып, каенанам белән алсагыз гына инде, дия торган идем. Шөкер, инәй белән әйбәт яшәдек. «Әле дә син бар, Гөлсәрия», – дияр иде. Мине бик яратты ул. Эштән бераз соңга калсам, эзләп чыгар иде.

Каенанасы үлгәндә янында була алмаганына әле дә борчыла Гөлсәрия апа. Шулай тиз һәм кинәт кенә ташлап китәр дип уйламый да ул. 2007 елның 28 декабрендә 78 яшендә мәңгелеккә күзләрен йома каенанасы.

– Ул көнне авылда бал-маскарад иде. Мин шунда чыгып киттем. Озак та үтмәде, улларым килеп җитте. «Әби әллә нишләде», – диләр. Өйгә кайтсам, инәй үлгән иде инде, – дип әрнеп сөйли Гөлсәрия апа. – Соңгы сулышын алганда янәшә була алмадым. Бик үкендем инде шуңа. Үзе һәрвакыт ансат авыру, тиз үлем тели иде. Аллаһы Тәгалә аны ишеткән. Күзгә карап тилмереп ятмады. Ризабәхилдер инәй.

Ире дә ризадыр Гөлсәрия ападан! Бәхетен балаларда тапкан бит ул. Гомер буе сөйгән ярына тугры калып яшәве дә сокланырлык. Кул арасына керү белән йорттагы бөтен ир эшен балалары башкара. Башта бер төрле трактор алалар, аннан икенчесен, аннан башкасын. 30 гектар җирләре дә бар. Шунда малларга азык әзерлиләр. Ике улы гел ярдәм итеп тора. Илнуры янәшәдә генә зур итеп йорт җиткергән. Фәнисе Чаллыда яшәсә дә, әнисен ташламый. Бөтен эшне бергә эшлиләр. Киленен мактап кына тора Гөлсәрия апа. Мактамый ни! Үзе дә – рәхмәт сүзләре ишетеп яшәгән килен бит ул! Каенана хәер-фатихасының кыйммәтен белә ул. Уллары хөрмәт итеп тора, бөтен авыл сокланып сөйли аны.

– Язмышым шулдыр дип риза булып яшәдем. Ирем бер генә бала иде шул ул. Әмма икенче-өченче буын туганнары күп аның. Алар мине якын итеп торалар. Бик тату яшибез, – ди Гөлсәрия апа. – Гомер бушка узмады. Бер дигән уллар үстердем. Әгәр үземне уйлап, ир эзләп йөрсәм, балаларымны югалтыр идем. Гомер буе алар матур яшәсен дип тырыштым. Үткәннәргә үпкәм юк минем. Үкенмәдем дә. Тик йөрәктә ярам гына бар. Әле дә Вәзифемне сагынып яшим. Их, минәйтәм, шушы йортта бергә картаеп булмады...

ТҮЗМӘСКӘ КИРӘК, БАЛАМ...

Каләм алып, хат язарга тәвәккәллләгәнче бик озак уйладым. Баштарак мине танып алырлар, якыннарым укыр дип кыенсынган идем. Соңрак бүтәннәргә гыйбрәт булсын, алар ялгышмасын дип язарга булдым.

Иремне бик яратып кияүгә чыктым. Очрашып йөргәндә бер тапкыр да сүзгә килмәдек. Талашуның ни икәнен белми идек. Кияүгә чыгуга бәбигә дә узып куйдым. Бар да яхшы иде. Яши башлагач кына бар да үзгәрде. Ирем башта вак кына әйберләргә бәйләнеп сүз әйтсә, соңрак тавыш зурга китә башлады. Гаиләдәге тавышларга да түзәргә өйрәндем. Иң авыры иремнең хыянәтен белү иде.

Бервакыт миңа өйдәге компьютер кирәк булды. Тиз генә документларны барлыйм әле дип кабызып җибәрсәм, экранда иремнең бер хатын-кыз белән язышкан «бит»е ачылды.Ниләр кичергәнемне белсәгез икән... Алай да барысы да ачыкланганын әйтә алмадым, батырлыгым җитмәде. Соңрак үземдә көч табып, бу хакта Илшатның үзенә әйттем. Үзенә әйтү ошамады инде. Нигә чит смсларны укыйсың дип тә кычкырды, мине гаепле калдырырга тырышты. Ничек булгандыр, акылына тиз килеп, тезләнеп гафу сорый алды. Гафу иттем. Без хатын-кызлар, шундый инде.

Бер айдан балабыз туды. Кызыбыз дөньяга килү тормышыбызны үзгәртер дип өметләндем. Тик күрәселәр алда булган икән әле. Бәби тапканда күп кан югалткач, гемоглобиным түбән төшкән иде. Хәлем юк, ә ирем булышырга атлыгып тормады. Хәтта киемнәрне машинада түгел, кул белән юарга кушты. Янәсе, суны күп тотам икән. Безнең ул чакта бала арбасы да юк иде. Ике айга кадәр кызымны кулымда күтәреп йөрттем. Ярый әле ул чакта янәшәмдә гел энем булды. Җитмәсә, каенанам да авырый башлады. Аны балалары чиратлап карады. Безгә дә чират элəгә бит инде. Тик әнигә карата мин начар сүзләр әйтә алмыйм. Авыру булса да, аек акыллы иде ул. «Түз, балам», – дип кенә торды. Ә менә үз әти-әниемә бер генә авырлыкны да сиздермәдем. Ирем читкә йөрүен дәвам итте. Тора-бара бөтенләй бәйдән ычкынды, кайтып, миңа кул да күтәрә башлады. Бик авыр чаклар иде. Акча җитми. Мин юләр, иремә ярдәм итим дип, 8 айлык баламны калдырып, эшкә йөрдем. Азалияне йә энем карый, йә аның дуслары, йә инде каенанам алып кала. Акча керә башлагач, яшәгән фатирыбызга ремонт ясарга тотындык. Кулдан килгәнчә, ярдәм итәргә тырыштым.

Сүз ярасы – бер хәл, берзаман тән ярасына түзеп булмый башлады. Бик каты итеп кыйнаганын әле дә оныта алмыйм. Күрше хатыны белән сөйләшеп торган өчен котырып, тукмап атты. Аннары тагын гафу үтенде. Ир белән хатын арасында була инде, ачу саклама, диде. Кичердем. Өч көннән кул күтәрү тагын кабатланды. Монысында, өй җылынсын дип, мич кабызган өчен гаепле булдым. Намаз укый идем, шул вакытта китереп сукты. Янымда кызым бөтерелеп йөри иде. Мине рәнҗеткәнне күреп, ул елап җибәрде. Күңел бик рәнҗеде. Иремнең кансызлыгына шаккаттым. Бергә матур итеп яшәрбез дип тырышкан идем бит! Ирем күп сөйләшеп тормады, баланы һәм әйберләреңне ал да, өйдән чыгып китегез, диде.

Менә шунда уйга калдым. Әти-әнигә ничек әйтим? Аларны борчыйсым килми. Кая барырга? Елап та булмый ичмасам, күңелем каткан. Ничарадан бичара, туганнарыма чыгып киттем. Аларга килеп кергәч кенә елап җибәрдем. Шуннан куркa-куркa гына әтиемә шалтыраттым. Ә ул: «Мин сине кемгәдер кыйнатыр өчен үстермәдем. Елама, кызым, хәзер киләм», – диде. Дәшми яшәвемә шаккаттылар, нигә алданрак сиздермәдең, диделәр.

Икенче көнне тагын әйберләремне җыеп алып кайттым. Яңа җирдә яңа тормыш башладым. Башта кеше фатирында яшәдем. Озак та үтмәде, ипотека алып түләп баруың хәерлерәк, дигән фикергә килдем дә, тәвәккәлләп, фатир алдым.

Ирем йөргән кешесе белән яши башлады. Ә мин Аллаһы Тәгаләнең юл күрсәтүенә сөенеп яшим. Тормыш кызык бит ул, бер алдын, бер артын күрсәтә дигәндәй, көннәрдән бер көнне иремне азындырып йөргән хатын миннән киңәш сорап шалтыратты. Күрәсең, кемгә килеп капканын аңлаган. Ялгыштым, холкы авыр, дип зарлана. Үзең теләп алган язмыш, дидем. Ул исә, беренче иремне сагынам, дип елый. Кемнеңдер бәхетсезлегендә бәхетле булып булмый шул.

Мин аңа рәнҗемим. Үзенә дә шулай дидем, рәхмәт сиңа, дидем. Шул хатын килеп чыкмаса, иремнең вакчыллыгына түзеп яшәр идем. Миндә сабырлык җитәрлек бит ул. Ә бүгенге хәлем шөкер итәрлек. Торыр урыным, эшләр эшем бар, әти-әнием исән-сау, бер дигән балам үсеп килә.

Әйтер сүзем шул: һәрвакытта да барган җирдә таш булып калып булмый. Әгәр сине рәнҗетәләр, мыскыл итәләр, авыр сүз белән йөрәгеңне яралыйлар, кул күтәрәләр икән, түзмәгез! Кеше ни әйтер дип түгел, үзеңне уйлап яшәргә кирәк. Без бит бу җирдә бер генә яшибез. Ниһаять, мин дә шуны аңладым.

Ландыш СИБГАТУЛЛИНА.
Тәтеш районы

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

< Дәвамы. Башы 28 апрель санында

– Камил Касыймович, Камилә сезнең янга керергә рөхсәт сорый.

– Рөхсәт.

Секретарь чыгып киткәч, Камил хатны тиз генә өстәл тартмасына шудырды. Камилә кабинет ишеген ачканда, ул җитди кыяфәт чыгарып, җитәкче роленә кереп өлгергән иде инде.

Камилә төс-кыяфәт белән әнисенә охшаса да, үткерлеге аныкы түгел, күренеп тора. Камил беренче көн эшләмәгән җитәкче буларак, аңа үзе ярдәмгә килде.

– Йомышыгыз бар идеме?

Камилә оялып кына сүз башлады.

– Әнинең сезнең белән күрешеп сөйләшәсе килә. Әгәр риза булсагыз...

Камилнең бөтен тәне эсселе-суыклы булып китте. Ләкин «...күлмәге дә сәрпинкә, алтын чәчле, зәңгәр күзле – коеп куйган кәртинкә» Камилә каршында коелып төшмәде.

– Оясында ни күрсә, очканында шул булыр, димәкче буласыңмы? Әйе, синең сүзләрдә дә хаклык бар, Фәнәзия.

Кичке аш артында да сүз күбрәк Газинур турында барды. Бу минутларда Фәнәзия белән Камил аларга тормыш әзерләгән «сюрприз»лар турында белмиләр иде әле.

Фәнәзия инде ярты сәгать элек рәхәт изрәп йоклап китте. Камил, хатынын уятмаска тырышып, йокы бүлмәсе ишеген акрын ябып, зал ягына чыгып утырды. Тавышсыз гына телевизорны кабызып куйды. Ачык калган форточкадан якындагы шәһәр шау-шуы ишетелеп тора. Өй эченә тулган көз исе күңеленә рәхәтлек бирсә дә, Камилне моңсу уйларыннан арындыра алмады.

Яуһәрия... Яуһәрия... Ничә еллар җигелеп тарткан тормыш арбасының бер ягы китек булган түгелме соң? Хатынына өйләнешкәннән бирле бер тапкыр да «Яратам!» дип әйтә алмавы, Яуһәриягә

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

СИН КЕМ КЫЗЫ?

– Әниегез кайчан килергә уйлый?

– Ул унбиш көнлек ял алган иде, шуңа иртәгә үк килеп җитә ала... Сез теләсәгез.

– Әниегезне мин, кайчан килсә дә, кабул итәм, шулай дип әйтегез.

Камилә йомышының шулай тиз үтәлүенә үзе дә ышанырга белми, рәхмәт әйтеп, кабинеттан чыгып китте.

«Кызык, сентябрь башында укытучылар эш башлый гына әле, ә Яуһәрия ялга чыккан. Хәер, укытучы булып эшләмәскә дә мөмкин бит». Камил Яуһәрияне исеннән чыгармаса да, аның белән очрашу эзләп, тормышы белән кызыксынып яшәмәде. Яуһәрия үзе шулай теләде.

Көндәгедән иртәрәк кайткан Камилгә Фәнәзия аптырап китте.

– Әтисе, иртәләгәнсең, минем әле кичке ашым да әзер түгел.

– Зыян юк, көтәм, әнисе. Эчемдә ач бүреләр уламый.

Аннан уллары Газинур бүлмәсенә ымлап:

– Өйдәме? – дип сорады.

– Гөлгенәсе ниндидер концертта катнаша, лекцияләрдән соң библиотекага, аннан – филармониягә, дип чылтыратты.

Аннан Камилдән шикләнебрәк:

– Бер-бер хәл булдымы әллә? – дип куйды.

– Юк, әнисе, бар да тәртип. Газинур быел соңгы курсын башлады бит. Планнарын сорашмакчы идем, эшкә кермәкчеме, укуын аспирантурада дәвам итмәкчеме? Гөлгенәсе белән ни уйлый икән?

Фәнәзия сәгатькә күз салды. Җиде туларга унбиш минут чамасы. Тутырылган борыч, димләмә, ярты сәгатьтән генә әзер булачак әле. Алъяпкычын аш-су бүлмәсенә илтеп куйды да Камил янына килеп утырды.

– Син ничек уйлыйсың соң үзең?

– Фән белән кызыксынуы көчле бит, аспирантурада калам, дисә, мин каршы түгел.

– Ә өйләнәм дисә?

– Ә син каршымыни? Оныклар да булса, ишәябез, шәп кенә була бит, ә, әнисе!

– Каршылыкка каршы түгел дә, иртәрәк булмасмы димен, егерме ике яшь кенә тулды бит әле Газинурга. Аннан Гөлгенәсен дә ныклап белеп бетермибез, ниндирәк гаиләдән икән?

– Бер-берсен яратсалар, анысы мөһим түгел, минемчә.

– Алай димә, әтисе, балаларда гаиләнең холкы чагыла.

биргән антының тотып торуы түгел микән?! Югыйсә Фәнәзиясе бик лаек бит ул сүзгә. Әтиләре көчләп диярлек таныштырсалар да, үзләре килешеп, ЗАГСка гариза илттеләр. Яуһәрия кырт өзеп, диплом алган иkенче көнне үк авылына кайтып китмәсә, Камил артыннан баргач, качып калмаса, соңыннан күрше республикага китеп эшкә урнашмаса, кем белә, бәлки, тормыш арбасы бөтенләй икенче юлдан тәгәрәр иде. Егыласымны алдан белсәм, салам җәеп куяр идем, дигән әйтем бар-барын, әмма шул ук вакытта татарда «һәркемнең үз язмышы» дигәне дә бар.

Яуһәрия Камилнең әтиләре сүзеннән чыга алмасына Камилнең үзеннән дә ныграк ышанган булган, күрәсең. Фәнәзия турында иң беренче сүз чыкканнан бирле алыштырып куйган кебек булдылар шул Яуһәрияне. Бигрәк тә май бәйрәмнәреннән соң, юк-бар сәбәп табып, Камилне тизрәк озату ягын гына карый башлады. «Нигә әйтергә кирәк булган инде миңа әтиләр белән Фәнәзияләргә кунакка барганны», – дип үзен битәрләп тә йөрде Камил соңыннан. Иң гаҗәбе: ул Фәнәзияне ошатты. Юк, чибәрлегенә ушы китмәде. Ул вакытта Яуһәрия аның күзен томалаган, башкаларны күрү дәрәҗәсендә түгел иде Камил. Кечелеге, гадилеге, нәзакәтлелеге сокландырды. Яши башлагач, башка гүзәл якларын да ачты хатынының. Тик ни өчендер «яратам» дип әйтергә теле әйләнмәде.

Яуһәрия... Яуһәрия... Тәннәребез дә җаннарыбыз кавышканга кушылды бит. Мин сине мәңге ташламаска ант иттем. «Яуһәрия авырлы, без өйләнешәбез», – дип әйтергә икуләп план кордык, син каршы килмәдең. Ә аннан соң икебез дә диплом яклау мәшәкатьләренә чумдык... һәм аерылдык.

***

Секретаре: «Камил Касыймович, Яуһәрия Ризванова сезгә керергә тели», – дигәч, Камил торып ишеккә таба атлаганын сизми дә калды. Оксана аптырабрак, читкә тайпылды.

Ишекнең теге ягында шактый гына таза гәүдәле, кара бөдрә чәчле хатыннан башка беркемне дә күрмәгәч: «Яуһәрия Ризванова үтсен, кайда ул?» – дип сорарга мәҗбүр булды.

Кабул иту бүлмәсендә басып торган хатын: «Исәнмесез, Камил Касыймович, мин булам Яуһәрия Ризванова, керергә рөхсәтме?» – дип дәшкәч, Камил каршында басып торган хатыннан таныш чалымнар табарга тырышты. «Егерме өч ел үтсә дә, кеше бу кадәр үзгәрмәс, Яуһәрия түгел бу хатын». Алар кабинетка үттеләр.

– Аптырадыгыз, күреп торам.

– Әзрәк бар.

– Сез бит мине түгел, икенче Яуһәрияне көттегез.

– ...

– Кызганычка, аның мәрхүм булганына унбиш ел.

– Ничек мәрхүм?!

Ир-егетнең эчендә җигүле атлар ятар, ди. Район дәваханәсендә хәтсез еллар баш табиб булып эшләүче Яуһәрия Ризванова моны бик яхшы аңлый иде. Шуңа күрә ул дилбегәне үз кулына алды. «Камил Касыймович, сез белгән Яуһәрия яман шеш авыруы белән китеп барды. Аякка баса алмавын аңлагач, миңа сезнең турыда сөйләде. «Берүк, минем бу дөньяда юклыгымны белдермәгез. Бик кирәк чагында гына әйтерсез», – дип үтенде. Ходай шул сәгатьне Камилә эшкә урнашкан вакытка тоткандыр инде».

Оксана чәй әзерләп кертте. Камилнең ут кебек кайнар йөрәген чәй генә басарлык түгел иде.

– Димәк, сез Камиләгә икенче әни булгансыз?

– Әйе. Исемнәребез туры килгәнгә генә түгел. Без аның белән районга эшкә бер елны кайттык. Ул – мәктәпкә, мин – дәваханәгә. Яуһәрия килеп, ике атна эшләүгә, мәктәп директоры Наилгә кияүгә чыкты. «Егерме сигез яшенә кадәр өйләнми, Яуһәрияне көткән икән Наил», – диделәр алар турында. Бик матур итеп яшәп киттеләр, Камилә туды. Яуһәрия кызын мин кизү торганда тапты. Ул вакытны мин балалар тудыру бүлегендә эшли идем. Хәзер инде баш табибмын. Наил роно җитәкче. Яуһәриянең бәхиллеге белән өйләнештек. Тагын ике ул алып кайттык.

Яуһәрия тынып калды. Аннан: «Монысын да әйтим инде», – дигән караш ташлап, сүзен дәвам итте.

– Мактана дип уйлый күрмәгез. Камиләнең тылы ныклыгын гына күрсәтәсем килә. Берүк әллә ни уйлый күрмәгез. Сездән берни дә таләп итмибез. Монда таныш-белешләребез юк дәрәҗәсендә, шуңа эшкә урнаштыру мәсьәләсе килеп чыккач, мөрәҗәгать итәргә уйладык. Рәхмәт яусын, булдыргансыз. Укып бетергәч, үзебезнең республикага кайтыра теләмәде шул Камилә, эш сөйләшенгән иде югыйсә. Әнисенең кендек каны тамган җир тартадыр инде балакайны. Әбиләренә дә моннан кайтып йөрү якынрак.

– Камилә әнисен хәтерлиме?

– Беренче класста укый иде, хәтерли.

– Ә әтисенең мин икәнен беләме?

Яуһәрия бу сорауны Камилдән көтмәгән иде. Киресенчә, сорауны Камилгә үзе бирергә әзерләнеп килгән иде ул. Кем кызы соң ул Камилә?

Яуһәрия Ризванова килеп киткәч, Камил өч көнлек командировкага китте. Әйләнеп кайткан кичне, эш сәгате тәмамланугa бер сәгатьләп вакыт узуга карамастан, вокзалдан туры оешмага китте. Исәбе Камиләгә дип алып кайткан бүләген анда калдырып чыгу иде.

Камиләнең үз кызы икәненә өмете сүнмәгән иде әле аның. Беренчедән, Яуһәрия, врач буларак, «Хатын-кыз баланы йөклелек срогы беткәнче табарга да, срогыннан артык йөрергә дә мөмкин», – дип аңлатты. Икенчедән, Камилә белән ниндидер хәл итеклә алмаган мәсьәлә килеп чыкса, Яуһәриянең аны эзләп табарга кушып калдыруы тикмәгә генә түгел иде.

Ахыры бар >

Шигърият

Фәрдия СӘФӘРГАЛИЕВА

ШАГЫЙРЬ МӘХӘББӘТЕ ҖАВАПСЫЗ...

Синнән миңа шигъри юллар булмас,
Мин кадерлең була алмадым...
Яннарыма килеп, сөеклем, дип,
Иңнәремә кулың салмадың...

Синең миңа җылы сүзең дә юк,
Назлы карашың да булмады.
Яшьләй сайлап алган ярым идең,
Бәхет китермәдең, уңмадым...

Синең белән иңне иңгә куеп
Узалмадым гомер юлымны.
Назлы сүзләремне «ишетмәдең»,
Син «күрмәдең» сузган кулымны...

Сулышыңны тоеп, кочагыңда оеп
Онытылырга насыйп булмады.
Очрашудан шашып, балкып янган
Күзләреңне күреп булмады.

Төшләрем дә чынга ашмас инде,
Бәхеткә бу, диеп юрасам...
Өзгәләнеп шигырь язмассың син,
Мәңгелеккә китеп югалсам...

МИН

Мин яралган изге мизгелләргә
Әткәм-әнкәм җыры кушылган.
Җанкаемны җырлар сугарганга,
Күңелемә моңнар тулышкан.
Ак каеннар шәлен ябынганда,
Гүли-гүли телем ачылган.
Тәүге адымнарым атлаганда,
Тирә-ягым ак кар ябынган.
Тәпи йөреп киткән чакларымда
Хәтфә чирәмнәргә басылган.
Җырлар җырлап тирбәткәндә мине,
Матур-матур сүзләр табылган.
Гомере буе яман күздән саклап,
Әнкәм теләк теләп табынган:
«Эчләрен иман аруласын», – дип,
«Тышларын су аруласын», – дип,
Ак мунчабызда коендырган.
Тап төшерми, каралтмыйча саклап,
Аклар өчен Әнкәм өметен,
Саф күңелем, чиста уйлар белән
Башладым язмышның һәр көнен.

САКЛАГЫЗ ӘНИЛӘРНЕ

Килер бер көн... Ул мәңгелек түгел...
Өзелеп чакырсаң да, килә алмас...
Бик сагынган минутларың булыр,
Тик әнием кире кайталмас...
Йокыларың бүлеп шалтыратмас,
Киңәшләрен биреп йөдәтмәс...
Ялгышудан йолып калыйм, диеп,
Дөрес юл сайларга өйрәтмәс...
Газизләрдән газиз балам, диеп,
Күз яшьләре аша эндәшмәс...
...Син кадерлә исәнендә аны,
Сорашып тор хәлен, иркәлә.
Бүген, бүген яшәвенә шатлан!
Соң булуы бар бит иртәгә...

ҮПКӘЛӘТТЕҢ...

Үпкәләттең, юк, рәнҗеттең мине,
Юлларыңа ятар җыр идем...
Бер мизгелдә барсын таптап узды̆ң,
Күктән төшеп җирләргә иңдем.
Җиргә иңдем шиңгән гөлләр сыман...
Узган көннәремә сарылдым...
Синнән башка, синсез яшәүләрнең
Бер яме юк миңа...
Сагындым...

«ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН»

медицина тикшеренүе узу өчен СЕРТИФИКАТ уйната

1 **ЯЗЫЛ!**
2023 елның икенче яртыеллыгына «ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН» газетасына язып

П2435 – җомга саны
512 сум 70 тиен
П2409 – атнага дүрт тапкыр чыга
1227 сум 30 тиен

2 **КВИТАНЦИЯ КҮЧЕРМӘСЕН БЕЗГӘ ҖИБӘР!**

89179270040 info@vatantat.ru
420097, Казан шәһәре, Академия урамы, 2 нче йорт.

3 **БҮЛӘК ОТ!**

Сертификатлар:
1) 9 төрле УЗИ+уролог консультациясе;
2) 9 төрле УЗИ+гинеколог консультациясе;
3) остеопат ярдәме.

Тулырак сайтта: vatantat.ru

Акция 2023 елның 28 апреленнән башлап 30 июнена кадәр дәвам итә.
Акцияне оештыручы – ТР ДБУ «Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

Реклама 16+

МЦ «НУРМЕД»

«Сәламәт хатын-кыз»
*АКЦИЯ ~~5 100 сум~~ **3 100 сум**

Анализлар. Кече оча әгъзаларына УЗИ.
Сөт бизләренә УЗИ. Гинеколог консультациясе.

*Акция 2023 елның 30 маена кадәр дәвам итә.

(843) 246-76-00
(843) 209-19-29

Адрес:
Салих Батыев ур., 1 йорт

Тулырак сайтта: nhkrt.ru

Реклама 18+

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШУ СОРАЛА.

Ераклык
Ишетмәүче
Мулла башында
Мадрид футбол командасы
Кыйбат түгел
Икенче нота
Төс
1906 елгы сатирик татар журналы
ТНВ сериалы

Арча ягында елга
Икмәк
Йошкар-...
Рус шагыйрәсе ... Әхмәтова
Кино актеры Камил ...
Антонов очкычы
Рим Хәсәнов җыры
Сидек
Вәгъдә
Ай күрде, ул алды
Бөртекле азык-төлек
Ул басмаса, мин басам
Эшкәртер материал
Әкияти батыр
Су һәм боз туганы
Тимер-аяклы Алинә
Казандагы микро-район
Буддистлар аксакалы
«Сандугачлар ... ясый, шуны күрәсем килә»
Блогер Ләйлә ...
Бераз тегенди
Татарстан саны
Конверт тышлыгында
...-Манш бугазы
Легендар боксчы



... чигү
Башны эшләтә
Аңгыра
Көрәшче җырчы Усманов
«... килде» спектакле
Тегермәнче порошогы
Җәясез кирәге юк
Авыл суы
«... Гра» музыкаль төркеме
Мин, ..., ул, алар
Тукайның туган авылы
Төрмә

Әз-мәз мәзәк

– Сәлам! Танышабызмы? Әйдә берәр кая барабыз!
– Мин майда бәбилим.
– Алайса, июньдә?

* * *

– Бәлки, калырсың?
– Юк, мин инде лифт чакырдым.

* * *

– Экспресс макияж нәрсә ул?
– Егетеңнән «мин килдем, чык әйдә» дигән смс килгәч эшләнелә торган гамәл.

* * *

– Миңа озак яшисе калдымы икән?
– Ку-ку! Ку-ку!
– Доктор, бар да яхшымы?

* * *

– Мин хатынымнан шикләнә башладым...
– Ник?
– Башка шәһәргә күчтек, ә өйгә һаман шул бер үк сантехник килә.

Сканворд җаваплары

Горизонталь: чалма, арзан, Реал, Карчыга, ипи, Анна, Ола, Лима, бәвел, ант, пар, кояш, оя, Алып, лама, иза, Али, ми, надан, Әни, он, Вәлиева, син, Кушлавыч.

Вертикаль: чукрак, Әкълимә, ук, Азино, Ларин, ярма, инеш, Алмаш, Ашыт, Ан, ВИА, тиле, ара, уналты, ре, Әпипә, Заһитова, адрес, ал, Лерон, Ла, Вил, чимал, зиндан.

Беләсең килсә...

1 Бу илдә су эчмичә 5 көн яши ала торган филләр бар:
а) Намибия;
б) Алжир;
в) Танзания.

2 Шәфталу белән кыз картинасын кайсы рәссам ясаган?
а) Иван Айвазовский;
б) Валентин Серов;
в) Андрей Рублев.

3 Коръәнне рус теленә тәрҗемә иткән Валерия Порохова үзенә нинди исем алган?
а) Мәдинә;
б) Иман;
в) Фатима.

4 «Джентльмены удачи» фильмын кем төшергән?
а) Леонид Гайдай;
б) Эльдар Рязанов;
в) Александр Серый.

Җаваплар: 1. а); 2. б); 3. б); 4. в).

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14266 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 263

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+